«Тыпыр-тыпыр китереп баса Мәхәббәт ноктасына»?!

Гадәттә, сәнгать советына тәкъдим ителгән дүрт-биш җырның берсе генә беренче тапкырдан худсовет аша уза. Нигездә, сүзләр аксый. Аранжировка, яздыру сыйфаты буенча да сораулар күп туа. Башкару – гомумән, аерым мәсьәлә. Нишләтәсең, беркемне дә җырлаудан тыеп булмый, андый закон юк. Үзем дә шул өлкәдә эшләгәнгәме, миңа хәзер бөтен татар кинәт кенә җырлый башлаган кебек тоела.

13 БИТ

Кешегә кое казы!

Норлат авылында яшәүче Госман Вәлитов 500ләп кое казыган. «Мин казыган иң тирән кое тугыз катлы йорт биеклегендә иде», – ди ул.

7 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 2.02.2017 | № 10 (5772)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

САТУЧЫ БАР, АЛУЧЫ ЮК

Чатырлы ярминкәләр ничек эшли?

Яңа елдан Казанда җиде урында көндәлек чатырлы ярминкәләр эшли башлады. Алар көзге, язгы ярминкәләр чорында гына түгел, кышын да, җәен дә эшләячәк. Тик «көндәлек» сүзе генә үзен акламый.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

5 БИТ

КИҢӘШ САНДЫГЫ

9 БИТ

АЗАТ АБИТОВ: «АВЫЛГА КАЙТЫП КИТМӘКЧЕ ИДЕМ, ВАҺАПОВ ФЕСТИВАЛЕ АЛЫП КАЛДЫ»

11 БИТ

РЕСПУБЛИКАДА

ЧИРМЕШӘН

Кыш дип тормыйлар, Кутәмә авылы урта мәктәбенең теплицасында кыякка суган, салат һәм петрушка үсә. Суган кыягын мәктәп ашханәсендә декабрь ахырында ук куллана башлаганнар. Февральдә исә редиска чәчәргә ниятлиләр, шулай ук помидор, чәчәк үсентеләре, кыяр да үстерергә уйлыйлар.

МӨСЛИМ

Район үзәгендә кичке чаңгы сәяхәте старт алды. Яктыртылган чаңгы юлы, дәрт биреп торучы музыка, җанатарлар – болар барысы да сәламәт яшәү рәвешен сайлаган мөслимлеләр өчен оештырылган. Чаралар циклы киләсе атналарда да дәвам итәчәк.

АЛЕКСЕЕВСК

Алексеевскида психологик-педагогик хезмәт эшли башлаган. Анда квалификацияле белгечләр: педагог-психологлар һәм логопедлар хезмәт күрсәтә. Әлеге хезмәтнең төп максаты – районның мәктәпкәчә балалар учреждениеләрендә һәм мәктәпләрендә эшләүче педагогларны, укучыларны һәм мәктәпкәчә яштәге балаларны, шулай ук аларның ата-аналарын психологик-педагогик яктан агарту. Бушлай психологик ярдәмгә балалар гына түгел, өлкәннәр дә мөрәҗәгать итә ала.

ӘЛКИ

Түбән Әлкидә яшәүче Наилә һәм Марат Гобәйдуллиннар бытбылдыклар үрчетә. 20 мең кошка исәпләнгән иркен ферма төзеп куйганнар. Алты инкубаторлары да бар. Гобәйдуллиннар бытбылдык асрауны бик отышлы шөгыль дип саныйлар. Бу бизнес 35 процентка кадәр табыш бирә. Гомумән, бытбылдык продукциясенә, бигрәк тә аның йомыркасына ихтыяҗ бик зур, диләр алар.

БАЛЫК БИСТӘСЕ

Көннәр салкын торуга карамастан, Янавыл авылы мәчетен төзү эшләре дәвам итә. Төзүчеләр мәчетнең манарасын күтәрүгә керештеләр. Шушы сөенечле вакыйгадан авыл халкы да читтә калмады. Һәр атнаның бер көнендә булса да, эшчеләргә чиратлашып төшке аш пешерү гадәткә керде.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

sntat.ru

Тырышканның даны чыга

Татарстанның өч крестьян-фермерлык хуҗалыгы «Иң яхшы гаилә фермасы-2016» россиякүләм бәйгесендә җиңү яулаган. Татарстанның Кукмара районыннан Роберт Дмитриев крестьян-фермер хуҗалыгы «50 башка кадәр» номинациясендә беренче урын алган. «100 башка кадәр» номинациясендә җиңүче дип Буа районыннан Алексей Кубайкин крестьян-фермер хуҗалыгы табылган. Биектау районы Торнаяз авылыннан Минсинә Латыйпова крестьян-фермер хуҗалыгы «200 башка кадәр» номинациясендә II урынга лаек булган.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Үзебезнең җиңүне Татарстан уңышы дип кабул иттем. Фермерларга хөкүмәт һәрдаим булышлык күрсәтә. Фермер һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясе рәисе Камияр Байтимеров эшләргә рухландырып кына тора. Конкурста катнашырга да ул тәкъдим итте. Сез булдырасыз, җиңәчәксез дә әле, диде. Җиңүебезне ике көн элек кенә хәбәр иттеләр. Әле дә шуны уйлап, үз алдыма елмаеп йөрим. Димәк, безне күрәләр, бәялиләр, – дип сөйләде безгә Минсинә ханым.

Латыйповларның гаилә фермасы 2009 елда теркәлгән. Бүгенге көндә аларның 250 баш эре терлеге бар. Аларның 130ы – савым сыеры, калган 120се – таналар белән үгезләр. 100 гектар пай җирләре бар, тагын 100 гектарын район арендага биргән.

– Җир мәйданнары күбрәк булса, сыерларның санын 400 башка кадәр арттыру мөмкинлеге дә бар. «Гаилә фермасы» программасында катнашып, ике зур ферма салдык, өч тракторыбыз эшләп тора. Сөтне, итне Казанга алып килеп ярминкәләрдә сатабыз, – ди хуҗабикә.

Бүгенге көндә аның крестьян-фермер хуҗалыгында терлек сую цехы бар. Цех тәүлеккә ун башка кадәр мөгезле эре терлек суюга исәпләнгән. Хуҗалыкта сезон вакытында тагын җиде кеше эшли. Төп ярдәмчеләре исә – балалары.

Ленар белән Минсинә Казанда укыганда танышканнар. Икесе дә авыл хуҗалыгы белгечлеген алган, берсе – ветеринар, икенчесе – зоотехник. Минсинә – Чувашиядән, Ленар Буадан булса да, аларны юллама белән Биектауга эшкә җибәргәннәр. Башта колхозда эшләгәннәр. Аннары гаилә фермасы төзегәннәр. Авыл хуҗалыгы белгечләре булгач, бу эшкә алар курыкмыйча, җиң сызганып тотынган. Гаилә эшләргә дә, ял итәргә дә вакыт таба. Балалары белән чит илгә ял итәргә дә йөреп торалар.

Минсинә Латыйпова крестьян-фермер хуҗалыгын һәркайда үрнәк итеп куялар. Тырыш гаилә «Агрорусь-2015» күргәзмә-ярминкәсе йомгаклары буенча алтын медальгә дә ия булган.

Сүз уңаеннан, «Иң яхшы гаилә фермасы-2016» конкурсына Россиянең 11 төбәгеннән катнашканнар. Шулардан 28 крестьян-фермер хуҗалыгы икенче этапка узган.

Шәһәр кәефе

НИЯЗ РАХМАН,
тележурналист:

– Доминикан республикасыннан туристлык сәяхәтеннән кайтып кына төштек әле. Анда 30 градус эсселек хәзер, бөтен дөньясы яшеллектә. Диңгездә су коендык. Сәгатьләр эчендә кыштан җәйгә күчену әкият кебек инде. Татарча сөйләшеп баручы ике кешене очраттык, дөнья читендә ана телебезне ишетү шулкадәр рәхәт булып китте. Арчадан килгән туристлар булып чыкты алар. Җиде сәгать аерма, Казанга кайткач, өч көн иялэшә алмыйча йөрдем.

НАДЕЖДА КУДРЯШОВА,
хезмәткәр:

– Тумышым белән Апас районыннан мин. Казанда 1993 елдан, Киров районында яшим. Аллага шөкер, балалар күп туа хәзер. Бакчалар гына түгел, ишегалларында уен мәйданчыклары да кирәк. Туксанынчы елларда ишегаллары тып-тын иде бит. Сабыйлар белән тормыш күңелле. Яшь гаиләләргә эш урыннары бетмәсен, йортлар төзелсен. Әле үзем дә, әйбәт кенә фатирым булсын иде, дип хыялланам.

АБДУЛЛА ДУБИН,
пенсионер:

– Табигать шулкадәр камил ул, җаным. Анда һәр фасыл үз урынында. Табигатьне ботарлап, кеше үзенә генә зыян сала. Тормышта комсызланып яшәргә ярамый, ул бер яктан барыбер кителә. Кыш үзенчә матур. Салкын – чыныктыра, җылы – какшата. Кыш – «санитар» ул. Барлык микроблар, зарарлы бөҗәкләр кырылып бетә. Саф һавада йөрим, башкаларга да шуны киңәш итәм. Аллага шөкер, тормышка, балаларга куанып яшим.

ОЛЬГА ГУРАСПИШВИЛИ,
экскурсовод:

– Әтием грузин милләтеннән, Казанда институтта югары белем алгач, монда калган. Кызганыч, әтием бик иртә бакыйлыкка күчте. Сагынабыз аны. Грузиягә барганым бар, Казан – туган шәһәрем. Соңгы елларда Кытайдан, Германиядән һәм Франциядән туристлар саны артуы күзәтелә. Европа кешеләре Казанда ислам, христиан, католик диннәре гыйбадәтханәләренең янәшә торуларын күреп шаккаталар.

ВЛАДИМИР ДЫННИК,
хезмәткәр:

– Алтайда тудым, 20 яшькә кадәр анда яшәдем. Казанда 1979 елдан хезмәт куям. Казан шәһәр төзеклеге ягыннан Мәскәү белән бер дәрәҗәдә, дип саныйм. Әмма юл хәрәкәтендә тәртип саерак. Дорфа кешеләр дә шактый очрый. Үзара дустанә мөгамәләдә булсак иде. Алтай тауларына барып кайтасы килә. Россиядә тарихи, матур урыннар бик күп. Күңел дәфтәремдәге планга «Кырымга барырга» дип яздым. Бу хыялымны да тормышка ашырачакмын.

Бәяләр үзгәрә

Әлегә кадәр Казанда вакытлыча автомобиль куела торган муниципаль парковка өчен сәгатенә 50 сум түләгән булсак, 1 марттан ул 30 сумнан 70 сумга кадәр булачак, дип хәбәр итә «Татар-информ». Бәяләр парковкага бирелгән категориягә бәйле булачак. Сәгатенә 30 сум тәшкил итәчәк минималь түләү – биш урында, ә 70 сум булачак максималь түләү җиде урында кертелә. Казанның калган 59 муниципаль машина кую урынында бәяләр элеккечә – сәгатенә 50 сум кала.

Искәртеп үтик, хәзерге вакытта Казанда муниципаль парковкаларга 71 урын билгеләнгән һәм анда 2092 машина куеп була.

30 СУМЛЫК ПАРКОВКАЛАР

М.Худяков, Г.Камал (Нариманов урамы киселешеннән Тукай урамы киселешенә кадәрге урында ике яклап; Тукай киселешеннән Мәскәү урамы киселешенә кадәр урамның так ягында), Г.Исхакый (Чернышевкий урамы киселешеннән Р.Яхин урамы белән кисешкән урынга кадәр урамның так ягында: Чернышевский урамы киселешеннән Т.Гыйззәт урамы белән кисешкән урында ике яклап) урамнарында.

70 СУМЛЫК ПАРКОВКАЛАР

Профессор Нужин урамы (2нче йорт янында), Театральная урамы (Дзержинсикй урамы киселешеннән Зур Кызыл урамы белән кисешкән урынга кадәр ике яклап), Толстой урамы (Горький урамы киселеше белән Маркс урамы киселешенә кадәр урамның җөп ягында; Маркс урамы киселеше белән Зур Кызыл урамы киселешенә кадәр урамның так ягында;), Ирек мәйданында (Маркс урамы буйлап Пушкин урамы киселеше белән Театральная урамы киселешенә кадәр), Толстой урамы (Щапов урамы киселеше белән Горький урамы киселешенә кадәр урамның җөп ягында), Профессор Нужин урамы (УНИКС бинасы каршында урамның так ягында), Толстой урамында (Бутлеров урамы киселеше белән Щапов урамы киселешенә кадәр урамның җөп ягында).

sntat.ru

«КАЗАН ОЛИМПИЯ УЕННАРЫН ҮТКӘРӘ АЛАМЫ?» – ДИП СОРЫЙЛАР. ӘЛБӘТТӘ!

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Татарстанның Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы коллегиясендә

ТОП – 5

ТИЗДӘН WhatsApp мессенджерында җибәрелгән хәбәрне юкка чыгару һәм үзгәртү функциясе барлыкка киләчәк, дип яза «Татар-информ». Хатны алучы хәбәрне ачып укыганчы ук, аның эчтәлеген үзгәртеп йә булмаса аны бөтенләй юкка чыгару мөмкин булачак. Моннан тыш, WhatsApp аралашу вакытында әңгәмәдәшеңнең хәзер төгәл кайда булуын күрсәтә торган функцияне эшләү белән мәшгуль. Әлегә бу функцияләр сынау этабын уза һәм моның кулланучыларга кайчан барып ирешүе турында хәбәр ителми.

РЕСПУБЛИКАДА язгы кыр эшләрен уңышлы башкарып чыгу өчен 20 миллиард сум акча кирәк була. Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов хәбәр иткәнчә, югары уңыш җыеп алу өчен һәр гектарга кимендә 9 мең сум акча тотарга кирәк. Бу суммага минераль ашламалар, ягулык-майлау материаллары, үсемлекләрне һәм микроашламаларны саклау чаралары, запас частьлар һәм хезмәт хакы керә.

2016 ЕЛДА Татарстанда бирелгән барлык кредитлардан автокредит күләме 60,5 процент тәшкил итә. Сүз яңа машина сатып алуга бирелгән кредит турында бара. Россиядә, үткән ел белән чагыштырганда, автокредит 13,8 процентка күбрәк бирелгән. Кредитка 552,4 мең яңа машина сатып алынган.

РОССИЯ хөкүмәте «Куркынычсыз юллар» проектын тормышка ашыруга 30 миллиард сум акча бүлеп биргән. Федераль бюджеттан Татарстанга 1 миллиард 825 миллион сум акча тия. «Куркынычсыз юллар» проекты «Бердәм Россия» партиясе тарафыннан эшләнгән.

РОССИЯ туристлары киләсе айда Мисырга оча алачак. 8-9 февраль көннәрендә Россия авиациясе контроль тикшерүләр үткәрәчәк, дип яза «Татар-информ». Шуннан соң Россиядән бу илгә очучы чартер һәм даими рейслар яңартылачак. Россиялеләр өчен Мисырның өч шәһәрендә аэропортларны ачу датаклары карала. Каир кабул итәргә әзер, ә Шарм-әл-Шәех һәм Хургадада 8-9 февраль көннәрендә куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча контроль тикшерүләр үтәчәк.

ШАККАТКЫЧ

130 хатынлы ир вафат

Нигериядә Әбүбәкер исеме белән танылган дингә өндәүче Мөхәммәд Беллога 93 яшь булган, дип яза gailya.ru, «Аль-Арабия»гә сылтама ясап. Аның 86 хатыны тол калган. Коръән дүрт хатынга гына өйләнергә рөхсәт итә, әмма Әбүбәкер күп хатынга өйләнгән өчен Изге китапта җәза каралмавы хакында әйтә торган булган. Үзенең тиз гашыйк булучанлыгын ул шулай аңлаткан. Дин таратучының 200 баласы һәм бихисап оныклары бар. Җирле басмалар хәбәр итүенчә, аның кайбер хатыннары әле дә бәби көтә.

«Салават күпере»нә – поездда

Быел Казаннан «Салават күпере» микрорайонына тимер юл төзи башлаячаклар. Бу проект шәһәрнең 60 мең кешесенә исәпләнгән иң эре микрорайонының транспорт проблемасын хәл итәргә булышачак, дип яза «РБК».

– Узган ел ахырында без Горький тимер юлы җитәкчелеге белән килешү төзедек. Шуның нигезендә, «Салават күпере» микрорайонына тимер юл тармагы төзергә уйладык. Тимер юл микрорайонны «Казан-2» станциясе белән тоташтырачак, – диде транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Ленар Сафин.

Аның сүзләренчә, «Казан-2» вокзалы – метроны да, тимер юл һәм җир өсте транспортын да берләштерә торган урын. Министр киләчәктә Казан тирәли барлык шәһәр яны бистәләрен үз эченә алган тимер юл божрасы барлыкка килү ихтималын да җиткерде. Соңгы вакытта шәһәр яны электричкалары халык арасында популярлаша бара, маршрутлар да арта икән. «Содружество» компаниясе, әйтик, 2016 елда 700 миллион керем алган. Тагын бер яңалык: тест рәвешендә пассажирлар агымы мониторингының автоматлаштырылган системасы эшли башлаган. Ул билетсыз йөрүче пассажирларны киметергә булышачак. Шуны да искәртергә кирәк: Татарстанда тимер юл транспортына бәяләр Идел буе округында чагыштырмача түбән. 9 чакрымлы зона өчен ул 13,7 сумны тәшкил итә.

АТНА ФОТОСЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Заманча яңгыраштa

Роскомнадзор мәгълүматлары буенча, Татарстанда 1039 массакүләм мәгълүмат чарасы теркәлгән. Шуларның 87се узган ел гына барлыкка килгән, ә 137 массакүләм мәгълүмат чарасы, киресенчә, эшчәнлеген туктаткан. Эшләүдән туктаганнарның күбесе – реклама-күңел ачу юнәлешендә эшләгән басмалар. Мәсәлән, әле кайчандыр халык арасында популяр булган «Из рук в руки» реклама басмасының тиражы 30 меңнән 5 меңгә кадәр кимегән. Шуңа күрә бүген ул интернет киңлекләрендә генә эшли.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Әлеге мәгълүматларны кичә «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы утырышында аның җитәкчесе Айрат Зарипов җиткерде. Гомуми абунәчеләр саны 1 млн 233 меңгә җиткән.

– Шулай ук интернет һәм радио да халык арасында бик популяр. Халыкның 75 проценты интернетка керсә, россиялеләрнең 65 проценты радио тыңлый, – диде Айрат Зарипов. – Республикада рус, татар, чуваш, удмурт телләрендә 650 басма матбугат чыгарыла. Аларның гомуми тиражы 1 млн 233 мең данәне тәшкил итә. Татарстанның бер мең кешесенә уртача 314 данә басма туры килә. Ә Россия буенча күрсәткечләргә килгәндә, бу сан 129ны тәшкил итә.

Газетага язылучылар санын арттыручылар арасында «Шәһри Казан» газетасы да телгә алынды. Исегезгә төшерәбез, безнең газетаның пәнҗешәмбе санын алдыручылар саны 22 процентка артты.

Моннан кала, Татарстан медиакырында «Казан» телерадиокомпаниясе нигезендә тәүлек буена эшләүче һәм сәгать саен яңалыклар җиткереп торучы «Татарстан 24» телеканалы эшли башлавы, Татарстан китап нәшриятының яхшы күрсәткечләргә ирешүе турында да әйтелде. Ә февральдә «Татарстан 24» телеканалы – Яшел Үзәндә, апрельдә – Чаллы, Түбән Кама, Биектау һәм Зәйдә, майда Әлмәт, Лениногорск, Буа, Баулы, Нурлат җирлекләрендә челтәрле тапшыруларга күчәчәк.

– Узган ел Татарстан китап нәшрияты өчен мөһим вакыйгаларга бай ел булды. Безнең беренче максат социаль яктан мөһим булган проектларны тормышка ашыруга юнәлтелгән. 2016 елда 226 данә китап бастырып чыгарды. Аларның тиражы 500 меңгә якын булды. Елның мөһим нәтиҗәләренең берсе – сатудан кергән табышның артуы. Һәм шуңа бәйле рәвештә, төрле дәрәҗәдәге салымнарның күләме арту. Сатудан кергән табышның суммасы узган ел белән чагыштырганда – 22,5, ә салым түләү 21,5 процентка артты. Татарстан китап нәшрияты тарихында беренче тапкыр гомумроссия максатчан программасы буенча китап нәшер итүгә акча бүлеп бирелде. Аның суммасы 550 мең сумны тәшкил итте, – диде Татарстан китап нәшрияты генераль директоры Илдар Сәгъдәтшин.

Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров «Тәртип FM» радиосы язмышына бәйле дә үз фикерен җиткерде.

– Дөресен генә әйткәндә, без бу темаңы күздән ычкындырдык. Кайбер иптәшләр, ә хәзер иптәшләр дә түгел, безнең ресурсларны да кулланып, татарча эшләячәк дигән «яхшы» ният белән ешлык алып, аны «үстереп», читкә саткан. Рөстәм Нургалиевич моңа бик зур канәгатьсезлеген белдерде. Хәзерге вакытта без әлеге радионы саклап калу юлларын эзлибез. Халык бу радионы ярата, шуңа күрә мәсьәләнең чишелеш юллары табылыр, – диде ул.

Әсгать Сәфәров журналистларның тәҗрибәсен арттыру, аларны укыту мәсьәләсенә дә тукталды. Аның сүзләренчә, кайбер журналистлар «кайнар», сенсацияле, шау-шу кузгата торган материаллар артыннан куып, бәлагә юлыгучыларның хәлен тагын да катлауландыра. Мондый вакытта тегe яки бу хәлгә объектив бәя бирүегезне сорыйбыз, дип мөрәҗәгать итте җитәкче залда утыручы каләм ияләренә.

Коллегия утырышы ахырында Әсгать Сәфәров массакүләм мәгълүмат чараларында хезмәт куючыларга дәүләт бүләкләрен тапшырды. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат Әминов – «Фидакарь хезмәте өчен» медаленә, ә «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәтенә лаек булды.

Укытучыдан беренче ярдәм

Быелдан «Мәгариф турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертелгәннән соң, педагогларга куела торган таләпләр дә артты. Хәзер алар беренче медицина ярдәме дә күрсәтә белергә тиеш. Әлеге эш, Татарстанда Президент Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән, «Иминлек» проекты кысаларында гамәлгә ашырыла.

Эльвира МОЗАФФАР

Бу уку елыннан укытучылар, тәрбиячеләр өчен медицина ярдәменә өйрәтә торган сигез сәгатьлек курслар каралган. Дәресләр Республика клиник хастаханәсе каршындагы Симуляция үзәгендә бара. Биредә инструкторлар өйрәткәннәрне заманча манекеннарда сынап карау мөмкинлеге дә булдырылган. Укулар ике этапта бара. Беренчесендә видеодәресләр аша күнекмәләргә өйрәтсәләр, икенче өлештә укытучылар өйрәнгәннәрне практикада кулланып карый. Курслар узганнан соң зачет тапшырганнарга махсус сертификатлар биреләчәк.

Укытучылар үзләре исә, мондый дәресләрне соңгы тапкыр студент чакта укыган идек, дип искә ала.

– Без әлеге курсларны укытучыларның квалификациясен күтәрүгә юнәлтелгән махсус укулар кысаларында узабыз. 15 ел мәктәптә эшләү дәверендә, шөкер, укучыларга медицина ярдәме күрсәтергә туры килгәне юк. Бу курслар педагогларга кирәк. Без биредә аңын югалткан кешеләргә ярдәм күрсәтергә, ясалма сулыш алдырырга, пешкән урынны, җәрәхәтне эшкәртергә өйрәнәбез, – ди 6нчы гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Лилия Низамиева.

Татарстанның сәламәтлек саклау министры Адел Вафин әйтүенчә, беренче медицина ярдәмен күрсәтә белү укытучыларга мәктәптә генә түгел, гомумән, башка җәмгать урыннарында да кирәк булуы бар. Шуңа да ул укытучыларга намус белән, тырышып укырга кушты.

– Еш кына беренче медицина ярдәме күрсәтү кеше гомерен саклап калуда хәлиткеч роль уйный. Трассадагы юл һәлакәтләрен генә алыйк: күп очракта кеше ашыгыч ярдәм хезмәте килеп җиткәнче вафат була. Шуңа да укытучыларның бу күнекмәләрне үзләштерүе файдалы булачак. Курсларны узган, кызыксынып укыган педагоглар авыр хәлдә калган кешегә беренче ярдәмне күрсәтә алачак, югалып калмаячак. Бу проектны тормышка ашыруда теләктәшлек күрсәткән мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттаховка да зур рәхмәт, – ди Адел Вафин.

Быел республика буенча 19 меңгә якын укытучы беренче ярдәм күрсәтү кагыйдәләрен үзләштерсә, киләсе өч елда барлыгы 60 меңләп укытучы әлеге курсларны узар, дип ниятләнелә.

Газетабызның узган бер санында, фермерларга үзләре җитештергән продукцияне сату өчен Казанда ел әйләнәсендә эшли торган түләүсез сату ноктталары барлыкка киләчәк, алар җиде урында булачак, дип язган идек. Аның беренчесе сентябрь аенда ачылды. Яңа елдан соң көндәлек чатырлы ярминкәләр бөтен җирдә дә тулы куәтенә эшли башлады. Алар көзге, язгы ярминкәләр чорында гына түгел, кышын да, җәен дә эшләячәк.

Сатучы бар, алучы юк

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

«Эко-фермер» авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы идарә рәисе Нурҗиһан Хәйретдинова безгә ул вакытта, сату ноктталары фәкать фермерлар өчен генә булачак, алыпсатарларга анда урын булмаячак, дип кат-кат басым ясап әйтте. Ярминкәләр шимбә, якшәмбедә генә түгел, көндәлек булачак, дип тә өстәде ул. Сәүдә ничек бара икән дип, сишәмбе көнне өч сату ноктасын карап кайттык. Атна уртасы булгангамы, сату итүчеләр юк иде. Зәкиев урамында урнашканында шимбә көнне сату булган, өстәл өстендә калган сөяк кыйпылчыклары шуны әйтеп тора. Фучик урамында чатырлар шулай ук буш, анда да ярминкә шимбәдә генә булган. Аның тирәсендә сату иткән әбиләр әйтүенә караганда, бирегә фермерлар килеп сата. Алар, чатырларның бик тә матур итеп ясалганын, утлар кертелгәнен дә әйтеп, өстәлләренең бик биек булуыннан зарланып алды. Өстәлләрен тәбәнәгрәк ясасалар, без дә шунда керепсату итәр идек, диделәр. Фермерларга дигән урында аларга сату рөхсәт ителәме икән соң? Казан мэриясенә без шул сорау белән мөрәҗәгать иттек. Чатырлы ярминкәдә республика авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре, фермерлар, крестьян-фермер хуҗалыклары, терлек асраучы, яшелчә үстерүче шәхси хуҗалыклар, бакчачылар сату итә ала, дип язылган безгә килгән җавапта. Өстәлләрнең биеклегенә килгәндә, Нурҗиһан Хәйретдинова әйтүенчә, алар барысы да фермерларның теләкләрен искә алып эшләнгән.

– Озынлыгы да, биеклеге дә кат-кат уйланып эшләнгән. Әлеге ярминкәләр иң беренче чиратта фермерларның мәнфәгатен күз уңында тота. Аларны булдыру идеясе белән фермерлар ассоциациясе һәм безнең кооператив чыкты. Сату урыннары кайда урнашачагын, аларның ни рәвешле булачагын без киңәшләшеп эшләдек. Әлбәттә, анда әбиләр дә сата ала, әмма бакчачылар кереп тулып, фермерларга урын калмаса, күңелле булмаячак. Ә боларны контрольдә тоту өчен, идарәче компания булдырырга кирәк. Без бу мәсьәлә буенча Казан шәһәре Башкарма комитетына да мөрәҗәгать иттек, әмма әлегә бернинди дә җавап юк. Сату урыннарын чиста тотарга, анда тәртип булдырырга, бәхәсләр чыкса, аларны хәл итәргә кирәк, башка хуҗалык мәсьәләләре белән дә шул компания шөгыльләнер иде. Ни өчен дигәндә, көз көне ул урыннарны бомжлар үз иткән дигән сүзләр дә ишетелде, – дип сөйләде ул безгә.

Идарәче компания булдыру турындагы сорау белән без Казанның Кулланучылар базары комитетына мөрәҗәгать иттек. Алар биргән мәгълүматлар буенча, мондый мөрәҗәгатьләр булган.

– Бу мәсьәлә өстендә эш бара. Якын араларда ачык конкурс игълан итәчәкбез, – диделәр безгә.

Нурҗиһан Хәйретдинова сату урыннарының әлегә алар теләгәнчә үк тулы түгеллеген дә әйтте.

– Реклама җитми. Атна уртасында анда килүче юк, шимбә көнне генә сату итәләр, – диде ул.

Шимбә ярминкәләре ничек уза икән дип, Лаврентьев урамындагы сәүдә ноктасына киттек. Суыктан куркып килмәгәннәрдер әле дисәм, Аксубайдан ук килүчеләр дә бар иде. Яңа Үзи авылыннан Фәнис Алимбәков ит белән сату итә.

– Бу урында сентябрь аеннан бирле сатам. Шәхси хуҗалыгымда 50 баш сыер асрыйм, 400 баш казны да шушыннан алып килеп саттым. Көзге ярминкәләр тукталды дип борчылып торганда гына, әлеге сәүдә ноктталары ел әйләнәсендә эшләячәк, дип сөендерделәр. Үстергән малны тизрәк урнаштырасы да килә бит. Хөкүмәтнең ярдәме зур. Авыл хуҗалыгы министрлыгы ай саен транспорт чыгымнарын каплый, ярминкәләрдә актив катнашучыларны бүләкли. Рәхәтләнеп эшлибез. Сәүдә урыннары бик җайлы, палаткалар корып утырасы юк. Әмма бер ягын каплаулы итсәләр, ышык булыр иде, – дигән теләген дә җиткерде ул.

Ярминкәләрнең көндәлек эшләвеннән ул хәбәрдар, ләкин Аксубайдан көн дә килеп йөреп булмый, өлгерә алмыйбыз, ди Фәнис абый. Халык та әлегә көн дә ярминкәгә йөрергә әзер түгел бугай, дип тә өстәде.

Балтач районы Түбән Кенә авылыннан Айдар Сәмигуллин бал сата.

– Бал сезоны бетсә дә, бүре гел урманга карап торган кебек, ярминкәгә чыгасы гына килеп тора. Ярминкәләргә актив йөргән өчен, Авыл хуҗалыгы министрлыгы 5000 сум премия дә бирде. Фермерларга теләктәшлек сизелә, – ди ул.

Пилмән ише ярымфабрикатлар сата торган ханым элек «Бәхетле» янында сату итүен, анда сәүдәнең яхшы баруын, ә бирегә сатып алучыларның аз булуыннан зарланып алды.

Зөядән килгән Газизә (фамилиясен әйтергә теләмәде) бирегә ноябрьдән бирле сата икән. Ул да, чатырлы сәүдә ноктталарының уңайлы булуын әйткәннән соң, «көндәлек» сүзенең үзен акламавын белдерде.

– Җомга көнне килеп карадык, сатып алучылар юк. Халык базарга, гадәттәгечә, шимбә көнне генә чыга. Булганнары да йокылары туйгач кына чыга бугай. Ә без монда кичкә кадәр басып тора алмыйбыз. Сатып алучы булса, һәр көн килер идек. Казан халкы бәлкем белеп тә бетермидер, реклама бирсеннәр иде, – ди ул.

Базарга чыгып ит сата башлаганнарына әле ярты ел гына икән. Моңа кадәр продукцияләрен алыпсатарларга тапшыра торган булганнар. «Үзең сатканда керемлерәк», – ди Газизә.

Арча районының Айван авылында яшәп, яшелчәчелек белән шөгыльләнүче Нәфил Гатауллин ярминкәләргә атна саен йөри. Ә менә аның таныш-белеш фермерлары ярминкәләрнең тукталмавын, анда сату өчен түләүсез урыннар барлыгын белмәгәннәр. Нәфилдән, шәхси хуҗалыклар да анда барып сата аламы, дип кызыксынганнар.

Чатырлы сәүдә ноктталары Лаврентьев базарының бер читендә урнашкан. Анда таба барганда базарның уртасыннан үтәсең. Кечкенә генә тәбәнәк өстәлләр өстенә сөт, эремчекләрен тезеп куйган Шәле апалары янына тукталдым. Нишләп чатыр астындагы өстәлләр янына басып сатмыйсыз дигән соравыбызга, бу урында дистә еллар сатабыз, халык безне шушыннан гына таба ала, диделәр. Тозлы кыяр, кәбестә сатып торучы абзыйга да шул ук сорауны бирдем. Ул әлеге урыннар турында белми булып чыкты. Аның каравы алыпсатарлар үз иткән ул чатырлы базарны. Бер дә кыенсынмыйча гына: «Мин – алыпсатар», – диде сөт продуктлары сатып торучы ханым. Нурҗиһан Хәйретдинова әйтмешли, боларны контрольдә тотарлык, реклама белән дә шөгыльләнерлек, хуҗалык мәсьәләләрен дә чишәрлек идарәче компания җитмидер монда, мөгаен.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Чатырлы ярминкә урыннары

Фучик урамы, 64; Липатов урамы, 7; Зәкиев урамы, 12; Дементьев урамы, 7; Беломорская һәм Гудованцев урамнары чаты; Батыршин урамы, 20; Лаврентьев урамы, 10 адреслары буенча урнашкан.

Алар иртәнге 7дән көндезге 12гә кадәр эшли.

Ахырзаманнан – ахырзаманга

Ишеттегезме әле, февральдә без гөнаһлы бәндәләрне ахырзаманның чираттагысы көтә ди бит. Ишетмәсәгез дә гаҗәп түгел, мин дә очраклы гына белдем. Өйгә килгән кунакларны озатканда, олы улымның: «Дөнья бетмәсә, очрашырбыз!» – диюе колагымны гына түгел, күңелемне дә сагайтты.

Йолдыз ШӘРАПОВА



Баксаң, интернет бу хәбәрдән мыжлап тора икән. Бу юлы Мәскәү Мәтрүнәсе әйткән ди дөньяның соңгы көне турында. Язмалар шактый, арада котыңны очырырлыклары да бар. Ләкин исем дә китмәде. Тәмугка күнгән шайтан төсле, без ул ахырзаман дигәннәренә өйрәнеп беттек бит инде. Иммунитетыбыз бар. Ничек, нишләргә кирәген ел саен чыгып килгән кинофильмнарда күрсәтеп, өйрәтеп тордылар. Менә мин үзем генә дә барлы-юклы гомеремдә әллә ничә «ахырзаманнан» исән калган кеше.

Мин хәтерләгән беренчесе 1982 елда «булды» аның. Без студентлар идек. Планеталар парады була дип, почмак саен сөйләделәр. Ул чакта да әллә ни исебез китмәде. Иптәш кызлар белән, студентларның төзелеш отрядына язылып, Әстерханга помидор җыярга киттек. Шактый акча эшләп, кызынып, коенып, ял итеп кайттык. Дөнья бетмәде.

Аннары адәм баласы яңа гасырны дер калтырап көтте. Нишләптер, ахырзаман шул вакытта була дип ышандырдылар. Яңа гасыр бусагасы шактый биек булып чыкты, аның аша кешене кеше иткән кайбер сыйфатлар үрмәләп чыга алмадылар. Шөкер, ахырзаман бу юлы да булмый калды.

Ахырзаманны икеле саны белән бәйләү гадәте бар. Мөхәммәд (с.г.с.) үләр алдыннан ике бармагын күрсәткән, диләр. Шуны истә тоталар, күрәсең. 2012 елда безне ахырзаманның чираттагысы көтеп торды. Монысын майя кабиләләре әйткән булып чыкты. Майя кабиләсенә рәхмәт инде, ел башында ук дисәләр, нишләр идең, ярый әле декабрь азакларында гына иде ул дата.

Ахырзаманлы 2012 елда ноябрь аенда мин Истанбулда булдым. Андагы танышлар белән саубуллашканда: «Дөнья бетмәсә, кабат очрашырбыз», – дигән идем, тегеләрнең күзләре маңгайларына менде. «Нинди дөнья бетү турында сөйлисең?» – дип, миңа айдан төшкән кешегә карагандай гаҗәпләнеп тордылар. Бездә ел буе җиде килештә төрләндергән ахырзаман турында боларның бөтенләй дә ишеткәннәре юк икән. Безнең ил халкының ахырзаманнан куркып туннары тузды инде, ә боларның беренче ишетүләре иде. Әйе, ахырзаманның анысы бик көттә булды. Берәүләр җир казып йортлар төзеде, икенчеләр ул көнне: «Ашау байдан, үлем Ходайдан», – дип, кибетләрдә качып калырга теләде. Кибет киштәләреннән тоз, шырпы, шәм, консерв кебек товарлар ялап алган шикелле юкка чыкты. Әйтерсең лә дөнья алай болай бетә-нитә калса, алар белән генә ерак барып була. Мескен кешеләр нишләргә дә белмәделәр: кайберләре кайгысыннан эчә башлады, кемнәрдер гөнаһларын ярлыкауны сорап, көне-төне намазлыкта утырды. Аллага шөкер, Ходай безне бу юлы да кызганды. 2012 елның 22 декабрендә кояш икенче яктан чыкмады, Җир орбитасыннан ычкынып, галәмгә очмады, без тагын исән калдык.

Инде менә 2017 – Әтәч елы башланыр-башланмас ук, тагын ахырзаман җитә дигән сүзләр ишетелә башлады. Элек елларның ике санына беткәне генә шомландырса, бу юлы аны да көтеп тормаска булганнар, күрәсең. Дөньяны быел ук бетереп куймакчылар. Кемгә кирәк икән ул мондый коткы тарату, болай да икътисади кризистан аптыраган халыкны өркетеп яшәү?! Кемгә кирәк икән ул кешелек дөньясының бетүе? Ә бит кешенең төрлесе бар: балалары, картлары дигәндәй. Психикасы да һәркемнең бер төрле түгел, артык нечкә күңелләләр дә шактый. 2000 елда дөнья бетә дигәнне ишеткәч, бер улым: «Миңа ун яшь тә тулмыймыни инде?» – дип, идәнгә ятып елаган иде. Ничек юатырга да белмәгән идек. Беренче юбилеена зур бүләкләр көткән малайга дөнья бетү хәбәре шулай авыр тәэсир иткән иде.

Дөрес анысы, көннәрдән бер көнне кешелек дөньясына нокта куелыр ул. Табигый байлыклар да саегыр, башланган әйбернең азагы да була. Ләкин галимнәр бу соңгы көннең датасын бик еракка күчереп куялар ич. Ә аңарчы кешелек бүтән планеталарга да юл салып, шунда күченеп яши башлар дип тә фаразлыйлар. Өлкәннәр әйтмешли, Алла язмаган эш булмас. Ходай ташламаса, бүре ашамас.

Дини китапларда да ахырзаман, аның олы һәм кече хикмәтләре турында күп язылган. Ләкин анда, акка кара белән, аның төгәл вакытын беркем дә белми, ул бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә мәгълүм диелгән. Шулай булгач, ахырзаман турында бу сүз куертулар буш сафсата гына булып кала түгелме соң?! Андый коткы таратучылар үзләрен Ходай урынына куймакчылармы әллә?! Тәүбә, тәүбә!

Ахырзаман турындагы ялган сүзләрнең куркыныч булуы да бар бит. Көтүче малай турындагы әкиятне искә төшерик әле. Анда малай: «Бүре килде!» – дип ялганлап, авыл халкын кырга йөгертә. Икенче юлы чынлап та бүре килгәндә, кычкырып караса да, ялганлый дип, ярдәмгә ашыгучы табылмый. Без дә шул малай хәлендә калмабызмы? Уяулыгыбызны югалтмабызмы, ахырзаман дигәненең чынына да ышанмый тормабызмы? Хәер, ышанып ни эшлисең инде, әнием әйтмешли, җиреннән-күгеннән чыгып китә алмыйбыз. Ислам китапларында, мөселман һәр көнен соңгы көне шикелле яшәргә тиеш, диелгән. Гөнаһ кылмыйча, алдашмый-урлашмыйча, кеше рәнҗетмичә, гадел һәм хәләл итеп. Бүген кайсыбыз шулай яшим дия ала. Бәлки, бу ахырзаман дигән хәбәрләр дә, шактый дилбегәдән ычкынган адәм баласын шушы бик кирәкле гамәлләрне кире кайтарырга, аны яшәеше турында уйланырга чакырып, махсус эшләнәдер?

Бәлки, бу изге Мәтрүнә карчыкка (Матрена Московская) берәр рекламадыр? Чөнки быел Монетный двор аның сурәте төшерелгән көмеш медальон чыгарды һәм аны сатуга куйды. Телевизордан да реклама ясадылар, миңа – гади татар хатынына, шул Монетный двордан әлеге медальонны тәкъдим итеп хат та килде. Андый хатлар җибәреп (конвертлар да кыйммәт бит хәзер) акча әрәм иткәнче, ул хатны аласы кешенең кайсы милләттән, нинди диннән булуын тикшерергә кирәктер инде ул. Чираттагы ахырзаманның шушы Мәтрүнә исеме белән бәйләнеше моңа ышанмавымны көчәйтте генә.

...Ахырзаманның февральдәгесеннән исән-сау калсак, чираттагысы октябрь аенда көтеп тора әле безне.

КҮРШЕЛӘРДӘ

5-7 апрель көннәрендә Башкортстанның Нефтекамск каласында Фәридә Кудашева исемендәге «Дуслык моңы» башкорт һәм татар җыры халыкара фестивале үткәрелә. Җыр бәйрәме географиясе елдан-ел киңәя бара. Анда Татарстаннан да яшь җырчылар күп катнаша.

* * *

5-8 майда Чувашстанның Комсомол районында бишенче тапкыр «Урмай-Зәлидә» төрки дөнья мәдәнияте халыкара фестивале үтәчәк. Быел ул Чувашстанда татар хәрәкәтенең иҗтимагый-мәдәни тормышына – 30 ел, Бөтентатар иҗтимагый үзәгенә – 20 ел, Чувашстан татарлары милли-мәдәни мөхтәриятенә 10 ел тулуга багышлана. 6 майда Урмай авылы мәдәният йортында фестивальне ачу тантанасы көтелә. Фестивальдә катнашучылар 7 майда төрле номинацияләрдә чыгыш ясаячак. Фестиваль 8 майда Чабаксарда Сабан туе республика милли бәйрәмендә гала-концерт белән тәмамланачак.

* * *

Мари Элның Бәрәңге районында татар теле һәм әдәбияты буенча республика олимпиадасы үткән. Анда җиңүчеләр дип табылган Регина Басыйрова, Илзия Хисмәтуллина, Альмирә Сәгыйтова, Лилия Гыйззәтуллина һәм Илсинә Газимова Казанда узачак төбәк олимпиадасында катнашачак.

* * *

19 мартта Киров өлкәсендә татар халык җыр һәм биюләренә багышланган «Нократ моңнары» VI төбәкара бәйге-фестивале үтәчәк. Малмыж шәһәрендә узачак чарада вокал һәм бию жанрлары номинацияләрендә, шулай ук төрле яшь категорияләрендә үткәреләчәк бәйгедә соло чыгышлар, ансамбльләр башкаруында халык җырлары, классик композиторларның һәм заманча композиторларның әсәрләре тәкъдим ителәчәк. Киров өлкәсендә бүген 45 меңгә якын татар кешесе гомер кичерә. Татарларның күпчелеге – Киров, Нократ Аланы, Сосновка, Малмыж шәһәрләрендә. «Нократ моңнары» фестивалендә ел саен Киров өлкәсеннән генә түгел, күрше Татарстан районнарыннан да татар җыр һәм бию ансамбльләре катнаша.

***

Ульяновскиның Татар мәдәнияте үзәгендә Барый Тарханов исемендәге II өлкә татар халык театрлары фестивале башланды. Фестиваль кысаларында, өлкәдәге татар үзешчән театрлары мартка кадәр Ульяновскида, чиратлашып, спектакльләр күрсәтәчәк. Барый Тарханов исемендәге тәүге фестиваль Ульяновскида узган ел февраль-апрель айларында оештырылган иде.

Кешегә кое казы!

«Үз гомеремдә 500ләп кое казыдым», – дип шаккатырды Яшел Үзән районының Норлат авылында яшәүче Госман абый Вәлитов. Лаеклы ялга чыкса да, яраткан шөгыле – кое казудан туктамаган әле ул. «Эшкә чыккач, рәхәтләнеп китәм, кешегә хәрәкәт кирәк», – ди үзе. 500 кое да чик түгел әле, димәк.

Эльвира МОЗАФФАР

Һәркемнең өенә су кергән бүгенге заманда кое кирәк тә түгел кебек. Баксаң, киресенчә, шәхси хуҗалыкларда кое казытучылар арта бара икән. Кайберәүләр – су бетсә дип, кемдер – ата-бабасы истәлеге итеп, икенчеләре мал-туарга су эчерер өчен дип казыта. Коедан торба сузып, өенә су кертүчеләр дә бар.

Су кайдан чыкса, коены шунда казыйлар, диме әле халык мәкале. «Сулы урынны күңел сизә», – ди Госман абый. Казлар кунакларга ярата торган урын кое өчен уңышлы санала, дип тә әйтәләр икән. Казыганда, гадәттә, 7-8 метрдан су бәреп чыга. Хәер, төрле урын бар.

– Иң тирән кое 28 метр тирәнлектә булды. 1x1 метр киңлектәге коены дүрт кеше бер атна казыдык, моны тугыз катлы йорт биеклеге белән чагыштырырга була, – ди Госман абый.

Су чыгасын сизә башлагач, эшчеләр өстән очлы борау төшерәләр. Кое нык булсын өчен, бурасын кирпечтән өяләр, ә аскы якка туфрак ишелмәсен өчен, тимер торба урнаштыралар. Апас, Кайбыч якларында сиртмәле коелар күбрәк кулланылса, Яшел Үзән районында барабанлы, чылбырлы коеларны еш ясаталар икән. Бер кое казыту уртача 35 мең сумнарга төшә. Коены көрәк белән казыйлар. Бу эштә иң куркынычы – өстән җир ишелү, балчык тулы чиләкне алып торган кешенең игътибарсызлыгы, коега төшерелгән арканның ныклы булмавы. Берсендә коедан күтәрелгәндә трос өзелеп китеп, Госман абый үзе дә умыртка баганасын имгәткән булган.

Әңгәмәдәшем тумышы белән Норлаттан ерак түгел урнашкан Бакырчы авылыннан. Госман абыйны хатирәләр, яшьлек еллары туган авылы урамнарына алып кайта.

– Әтием Фатыйх – сугыш ветераны. Яу кырыннан яраланып кайткан иде. Соңгы көннәренә кадәр бер аягында ядрә кыйпылчыгы йөртте. Кое казырга да аннан өйрәндем. 1976 елны хәрби хезмәттән кайткач, әти белән күрше авылларга эшкә чыгып киттек. Күпме кешегә йортлар салдык, коелар казыдык, – ди Госман абый.

Балта эшенә осталык, агачтан төрле могҗизалар тудыру сәләте дә әтисеннән күчкән.

Вәлитовлар җиде бала үсә. Әниләре Хәлимә апаны аеруча яратып, сагынып искә ала әңгәмәдәшем. Көтмәгәндә бакыйлыкка күчкән, аяныч төстә гомере өзелгән әнисе турында сөйләгәндә күзләре яшьләнә, тамагына төер тыгыла. Хәлимә әби 91 яшендә, әле җир җимертеп йөргән җиреннән, иске базга егылып төшеп, шунда җыелган суга батып үлә.

– Туган йортка кайткан саен, башта тәрәзәгә күз салам. Әнинең яраннары бүген дә шау чәчәктә. Шөкер, әти-әнием йортында утлар сүнми, төп нигезне саклаучы абыем Габдулла бар, – дип сөенә Госман абый.

Борынгылар, коега төкермә, теләңә төер чыгар, дип, коеларны кадерләп, саклап тотканнар, хәтта аларны күмәргә дә ярамаган. Кое казу исә дин буенча да саваплы гамәл булып санала. Бу һөнәр иңләре юк диярлек бүген.

– Үз гомеремдә 500дән артык кое казып, бары икесендә генә су чыкмады. Эшнең үз җае, рәте бар. Дәвамчыларым булсын иде дип хыялланам. Киңәләремә белгәннәремне өйрәтәм. Кое, су, чишмә – Аллаһы Тәгалә нигъмәтләре. Шуңа да халык аларга сак карасын, сулыкларның кадерен белсен иде, – ди Госман Вәлитов.

Кыш озакка сузыла

Көннәр кайчан җылытыр икән? Иртәгә тагын суык булырмы? Телевизордан «Хәбәрләр» тапшыруын караганнан соң, һава торышы турындагы мәгълүматны көтеп ала торган булдым. Күңелне җылытырлык сүз әйтмәсләрме, янәсе.

Дамир Бәдриев фотосы

Аларның сүзләренә караганда, шимбә-ял көнне тагын суыта. Көндез 18 градуска кадәр суык булачак. Әби-бабайлардан гына ишетеп белгән 40 градуслы салкыннар булмаса да, бер өйрәнмәгәч, 22 градусы да куркыта.

Кыш быел озакка сузылырмы, язны кайчан көтәргә дип, Кукмара районының Рудник авылында яшәүче Фәйзрахман Бариевка шалтыраттым. Ул, табигатьне ел дәвамында күзәтеп барып, ел фасылларының ничек киләчәген алдан фаразлап куя.

– 31 декабрьдә җылы булды, кыш озакка сузылачак. Түбә читләрендәге боз сөңгеләренең дә озын булуы шуны хәбәр итә. 1 февральдә көн аяз булса, яз иртә килә дигән сынамыш бар. Ул көнне кар төште, бу да кышның тиз генә чигенмәячәге турында сөйли. Февральдә кар артык күп яумаячак, көннәр артык салкын булмас кебек. Булса да, бернечә көн генә суытып алачак. Март аенда, гадәттәгечә, суыклар торачак. 20ләреннән соң гына җылытачак. Май ае бик җылы килергә охшаган. Июньдә яңгырлар булачак, ә менә июль коры киләчәк. Августның ничек булачагын февраль ае күрсәтер инде, – диде халык синоптигы.

Казан федераль университетының метеорология һәм климатология кафедрасы мөдире Юрий Переведенцев сүзләренчә, февральдә көчле суыклар көтелми.

– Көз көне халык күркып көткән аномаль суыклар да килмәде. Иң салкын көн Казанда Раштуада күзәтелде. Термометр баганасы 27 градуска кадәр төште. Декабрь белән гыйнварда һава температурасы нормадан бик аз гына түбәнрәк булды. Халык шуны сизәргә дә өлгерде һәм аларча кыш суык булды. Урамда чын кыш! Кыш шундый булырга тиеш тә инде. Шунысы әйбәт, җепшек көннәр, кар эреп, аяк аслары юешләнүләр булмады, – ди ул.

Быел Россиянең көньягында исә чынлап та аномаль суыклар булган, дип яза «Российская газета». Кичке температура анда 3-8 градус салкынлык күрсәткән. Җылы яклар өчен бу, дөрестән дә, суык. Синоптиклар әйтүенчә, моңа бөтен үсемлекләр дә чыдамый. Җимеш бирә торган агачлар, виноградлар, шулай ук коньяк пальмалары да зыян күрергә мөмкин.

Сүз уңаеннан: иң суык көн Казанда 1942 елның 21 гыйнварында булган. Ул көнне термометр баганасы -46,8не күрсәткән. 1979 елның 1 гыйнварында 45,3 градус салкын булган.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

Кыштан җәйгә кунакка йөрү зыянлы

Ял итәргә бару дигәндә, күпләр диңгез буйларын күз алдына китерә торгандыр. Чынлыкта исә климатны кискен үзгәртү кеше организмы өчен беркайчан да эзсез калмый. Кышкы салкыннан бер атнага гына булса да эссе җәйгә кунакка барып кайту бик күңелле кебек тә үзе. Шул ук вакытта кирәкме соң безгә үзебезнең организмыбызны шул тиклем газаплау. Барган очракта да, ким дигәндә, ике атнага барырга тырышыгыз. Шушы вакыт аралыгында гына организм климат үзгәрешенә ияләнә. Иң авыры – җылы климаттан соң кабат салкынга күнегү. Бигрәк тә балалар, ялдан кайткач, авыруга еш бирешә. Җәйне озынайтырга теләсәгез, җылы якларга иртә язда һәм көз көне барыгыз. Кыш айларында иң яхшысы – шифаханәләрдә ял итү. Биредә ял да итәсең, дәвалану курслары да файдага гына. Әллә кайларга барып та йөрисе юк. Республикада 45кә якын шифаханә-курорт учреждениесе исәпләнә. Алар арасында билгеле бер авыруларга гына махсуслашканнары да бар. Бүген шифаханәләрдә яшәү-ашау шартлары, дәвалау базасы, ял итү-күңел ачу программасы югары дәрәҗәдә оештырылган. Һәркайсында һәрдаим төзекләндерү эшләре алып барыла, елдан-ел тәкъдим ителә торган хезмәтләр саны арта. Шифаханәләрдә пенсионерлар гына ял итәргә тиеш дигән фикер дә дөреслектән бик ерак тора. Анда яшьләр дә, балалы гаиләләр дә рәхәтләнеп ял итә.

ЛЕЧЕБНЫЕ ПРОГРАММЫ:
«Дети – наше будущее» «Мужское здоровье»
«Здоровый кишечник» «Здоровье женщины»
«Стройная фигура» «Антистресс»
«Активный отдых» «Лечение гипертонической болезни»

Высококвалифицированные специалисты помогут вам в реабилитации заболеваний:
– сердечно-сосудистых (в т.ч. реабилитация больных с ИБС !);
– органов пищеварения;
– органов дыхания;
– нервной системы;
– опорно-двигательного аппарата;
– эндокринологических;
– гинекологических;
– оздоровление детей из группы риска по бронхолегочной патологии и др.

А ТАКЖЕ:
– иглорефлексотерапия
– остеопат
– суточное мониторирование ЭКГ, АД;
– оздоровление беременных группы риска;
– послеоперационное долечивание желудочно-кишечного тракта.
– реабилитация больных с ИБС;
– суточное мониторирование ЭКГ, АД.

ЛЕЧЕБНЫЕ ВАННЫ:
Жемчужные, РАДОНОВЫЕ, морские, хвойные, бишофитовые, скипидарные, йодобромные, сухие углекислые, нафталан.

ЛЕЧЕБНЫЕ ПРОЦЕДУРЫ:
Озокерит, парафин, физиотерапия аппаратная (в т.ч. ДЭНАС, биоптрон, лазер, электросон магнитотурботрон и др.), грязелечение, аэрофитотерапия, озонотерапия, гирудотерапия, галокамера, спелеокамера, ингаляции, ароматерапия, массаж, терренкур, ЛФК, кислородные коктейли, скандинавская ходьба.

В санатории созданы все условия не только для полноценного лечения, но и для комфортного отдыха:
– парикмахерская, косметологический салон, солярий, услуги маникюра, бассейн, сауна, фитнес-зал, фитобар;
– 4-разовое питание (заказное меню);
– организация досуга (дискотеки, экскурсии, просмотр видеофильмов, бильярд, теннис, библиотека, барбекю, катание на коньках, лыжах).

Отдыхающие размещаются в шестиэтажном корпусе на 200 мест. Для проживания предусмотрены: двухместные номера со всеми удобствами, двухместные номера люкс, номера для VIP-персон, специально оборудованные номера для инвалидов-колясочников. Лечебный корпус, столовую, бассейн и жилой корпус связывает между собой теплый переход.

Необходима консультация специалиста. Имеются противопоказания

Лицензия ЛО-16-01-002892 от 26.08.13 г. Реклама

Эш беләктә түгел – теләктә, теләк булса, беләк чыдар, диләр бит. Талкыш кәләвә ясау остасы Гөлназ Сәләхетдинова белән сөйләшкәндә, тел очыма шул мәкаль килде. Талкыш кәләвә ясаганнарын күргәнем бар, баллы камырны нәзек җепселләр барлыкка килгәнче бертуктамый ян-якка тарту өчен шактый тир түгәргә кирәк. Беләгең нык булмаса, бу эшкә алынып та торма. Гөлназ сер бирүчеләрдән түгел. «Баштарак куллар арый иде, хәзер инде күнектем, авырлыгын күрмим», – ди.

Талкыш кәләвә: пешерер өчен көч кирәк

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

Талкыш кәләвәне ничек ясаганнарын ул кечкенәдән әнисеннән күреп үскән.

– Әнием пешекче булып эшли. Моннан 30 еллар элек хезмәттәше, талкыш кәләвә ясыйм, булышырга килмәссеңме, дип, аны да чакыра. Шуннан әни үзе дә өйрәнеп китеп, һәр бәйрәмгә кәләвә пешерә иде. Соңгы елларда ул онытылып торды. Хәзер бит бәлеш, торт пешереп, токмач кисеп, пилмән ясап сатучылар күбәйде. Мин дә беркөнне әниемә: «Кәләвә ясасаң, мин аны сату эшен үз өстемә алыр идем», – дип ычкындырдым. Интернеттан махсус эзләнеп-карап утырдым, кәләвә ясаучылар бик сирәк. Көндәшлек юк диярлек. Бу идея әтигә дә ошады. Эштән кайткач, кич белән кәләвә ясый башладылар. Моның өчен күп көч кирәк, әни дә, әти дә кул хезмәте сорый торган эштә эшлиләр. Кәләвә бит ул бик нәзберек ризык, кайвакыт килеп тә чыкмый. Кәеф тә кырыла. Нишләп аларны борчыйм соң дип, мин бу эшкә үзем тотынырга булдым. Килеп чыкканчы бик нык тырышырга туры килде. Бармакларны пешерә-пешерә бер утыз тапкыр ясап карагач кына килеп чыкты, – дип сөйли Гөлназ.

Кәләвә пешерү өчен көч кенә түгел, сабырлык, күңелең тыныч булу да мөһим. Бу алтын кагыйдәне Гөлназ кечкенәдән белеп үскән.

– Әни кәләвә пешерә башласа, без кухняда аның үзен генә калдырып, шауламаска тырыша идек. Барып чыкса гына ярар иде дип теләп утырган хәтердә. Кәләвәне иртән-иртүк, балалар йоклаганда торып пешерәм. Өйрәт әле, дип сораучылар бар. «Өйгә кайтып пешереп карауга ук барып чыга торган эшме соң ул?» – дип тә өстиләр. Мин берничек тә гарантия бирә алмыйм, киресенчә, 100 процент ышанып әйтәм: беренчесендә үк барып чыкмаячак, – ди кәләвә пешерү остасы.

Талкыш кәләвә пешереп карарга җыенучылар өчен Гөлназ ак май түгел, сары май (топленое масло) кулланырга киңәш итә. Аны исә ул үзе ясый.

– Балның да бик сыйфатлысын алырга кирәк. Бер тапкыр алган бал бик әйбәт булып чыкмады. Кәләвә ясау өчен әлбә белән баллы массаның температурасы бер төсле булу кирәк. Пешерергә өйрәнгәнче, янында булыша торган бер кеше булса әйбәт. Баштарак миңа ирем булышты, хәзер үзем дә өлгерәм. Икең дә остарып китеп, син дөрес итмәдең, син озаграк эшлисең, дип әйткәләшә башлагач та кыен. Үзем генә эшләгәч, бары үзең генә гаепле, – дип елмая Гөлназ.

Талкыш кәләвә суыткычта ике атнага кадәр саклана. Аны суыткычтан чәй эчәр алдынан гына чыгарырга кирәк, шул чакта ул авызда эреп торачак.

– Талкыш-кәләвә татарның милли ризыгы саналса да, бу ризык турында ишетүчеләр дә, авыз итеп караучылар да сирәк. Татарстанга килүчеләр чәк-чәкне, кыстыбый, өчпочмакны белә хәзер. Туристларга аларны тәкъдим итә беләбез. Ә менә талкыш кәләвә күләгәдә кала, – ди яңа танышым.

Гөлназ киләчәктә бавырсак та пешереп карарга хыяллана.

– Әнием, кайсыдыр бер районда бик оста итеп бавырсак пешерүче бар, диде. Шуңа барып өйрәнеп кайтырга ниятлим, – ди ул.

Видеосы www.shahrikazan.com сайтында

1

2

3

4

5

Орлык чәчү өчен «әкәм-төкәм» ысулы

Моның өчен безгә «әкәм-төкәм»-нәрне урнаштырырга тәбәнәк савыт (пластик контейнер), ламинат астына салып калдырыла торган подложка (төзелеш материаллары сатыла торган кибетләрдә рулонлап сатыла), пинцет, кереш, целлофан капчык, туфрак кирәк була.

Эш өстәлөнә иске клеенка җәябез. Туфрак, су, орлык, кирәкле материалларны кул астына алып куябыз. Подложкадан 10 см киңлектәге тасма кисеп алабыз. Тасма өстенә 1 см биеклектә туфрак җәябез. Ул чәчелеп китмәсен өчен, кул белән баскалап алабыз. Бераз гына су да сибәргә ярый. Туфракны тасманың буеннан-буена җәяргә кирәкми, алай уңайсыз булачак. Башта 10 см арага гына җәегез. Тасманың беренче өлешенә туфракны җәйгәч, аның бер кырыена орлык чәчеп чыгабыз (пинцет ярдәмендә дә ярый) да бераз гына туфракка батырып куябыз. Орлык тасма кырыеннан 2 см ераклыкта булсын. Орлыклар арасы – 1-2 см. Орлык салып чыкканнан соң, тасманы рулон итеп төреп барабыз. «Әкәм-төкәм» барлыкка килгәч, таралып китмәсен өчен, кереш белән беркетәбез. Орлыклары өскә якта калырлык итеп махсус савытларга утыртып куябыз да су сибәбез. «Әкәм-төкәм» өстенә пакет кидереп куябыз. Әлеге парник ярдәмендә орлыклар тизрәк тишелеп чыга. Тишелеп чыккач, пакетларны салдырыгыз. Әлеге ысул белән помидор, баклажан, борыч, кәбестә, ташкабак, чәчәк орлыкларын утыртырга була. Пикировкалаганда исә рулонны чишеп кенә җибәрәсең.

Борыч утырту серләре

- Кайнар суда җылытылган орлыкның тишелеп чыгу гарантиясе зуррак. Аларны утыртыр алдыннан ике сәгать буена термоста тотыгыз. Суның җылылыгы 50 градус булырга тиеш.
- Орлыкларны батарея яки мич янында җылыту дөрес түгел. Алар артык кибеп китәргә мөмкин.
- Җылытыр алдыннан орлыкларны 20-30 минут марганцовка эремәсендә тотыгыз, аннары агып торган суда юып алыгыз. Пикировкалап утырганчы, орлыкларны аерым чүлмәкләргә утырту дөресрәк, чөнки борыч күчереп утыртканны яратмый.
- Орлык утыртыласы туфрак җылы булсын.
- Үсентеләр үсеп чыккач, аларга өстәмә яктылык булдыру кирәк.
- Бер-ике яфрагы чыккач, үсентене аммиак селитрасы белән тукландырыгыз.
- Грунтка утыртырга ике атна кала, туфракка составында азот, фосфор, калий булган ашлама кертегез.
- Үсентеләр чәчәк атканда биш процентлы мочевина эремәсе белән эшкәртегез.
- Борыч үсентесенә суны ешрак сибегез, әмма күп итеп түгел.
- Бәрәңге яки помидорны эшкәрткәннән соң, борычка тотыныр алдыннан, эш коралларын юыгыз, алардан авырулар күчәргә мөмкин.

Орлыкларны «терелтәбез»

Күп кенә бакчачылар яшелчә, чәчәк орлыкларының тишелеп чыкмавыннан зарлана. Аның сәбәпләре төрле. Орлыклар кибеттә дөрес сакланмаган да булырга мөмкин йә булмаса бакчачы аларны чәчкәндә хата җибәрә.

Орлыклар тиз генә, бернинди тоткарлыксыз тишелеп чыксын дисәгез, аларны термик ысул белән эшкәртегез. Орлыкларны марляга салып, җеп белән бәйлисең. Бер стаканга кайнар, икенчесенә салкын су саласың. Марля капчыкны, чиратлаштырып, ике стаканга батырып ике-өч минут тотасың. Кайнар су суынса, аңа кайнарны өстәп торасың. Биш-алты тапкыр кабатлагач, орлыкларны кәгазь өстенә җәеп киптерәсең дә алдан әзерләп куелган туфракка чәчәсең. Әлеге ысул белән эшкәртелгән орлыклар барысы да тигез булып тишелеп чыга. Вак орлыклы чәчәкләр, гадәттә, начар тишелә. Шуңа да аларны фитоспорин дигән препаратта чылатып алыгыз.

Бакчачыга ай календаре

ОРЛЫК ЧӘЧҮ ӨЧЕН УҢЫШЛЫ КӨННӘР

КУЛЬТУРА	ФЕВРАЛЬ	МАРТ	АПРЕЛЬ	МАЙ	ИЮНЬ
карбыз	3, 4, 5, 6, 16, 17	2, 3, 4, 5, 6, 7, 15, 16, 17, 31	1, 2, 3, 4, 9, 13, 17, 28, 29, 30	1, 9, 14, 15, 27, 28	5, 6, 7, 11, 12
баклажан	1, 2, 3, 7, 8, 16, 17, 28	2, 3, 6, 7, 14, 15, 16, 17	2, 3, 4, 9, 13, 17, 30	1, 9, 14, 15, 27, 28	5, 6, 7, 11, 12
ташкабак	3, 4, 5, 6, 7, 8, 16, 17	2, 3, 4, 5, 14, 15, 16, 17, 31	1, 2, 3, 4, 9, 13, 17, 28, 29, 30	1, 9, 14, 15, 27, 28	5, 6, 7, 11, 12
кәбестә	3, 4, 16, 17	2, 3, 6, 7, 14, 15, 16, 17	9, 13, 17, 18	9, 14, 15	5, 6, 7, 11, 12
бәрәңге	3, 13, 14, 15, 18, 19, 20	2, 3, 6, 7, 14, 15, 16, 17, 18, 19	14, 15, 16, 17, 18	1, 13, 14, 15, 23, 27, 28	11, 12, 20, 21, 30
суган	3, 13, 14, 15, 16, 17	2, 3, 14, 15, 16, 17, 25, 26	13, 14, 15, 16, 17, 18	13, 14, 15, 23	11, 12, 20, 21, 30
кишер	3, 13, 14, 15, 16, 17	2, 3, 14, 15, 16, 17, 25, 26	13, 17, 18	14. 15. 23	11, 12, 20, 21, 30
кыяр	3, 4, 5, 6, 7, 8, 16, 17	1, 2, 3, 4, 5, 14, 15, 16, 17, 31	1, 2, 3, 4, 9, 13, 17, 18, 28, 29, 30	1, 9, 14. 15, 27, 28	5, 6, 7, 11, 12, 15, 16
баллы борыч	3, 4, 7, 8, 16, 17	2, 3, 6, 7, 14, 15, 16, 17, 18, 19	2, 3, 4, 9, 13, 14, 15, 16, 17, 18, 30	1, 9, 13, 14, 15, 27, 28	5, 6, 7, 11, 12, 15, 16
редис	1, 2, 3, 13, 14, 15, 16, 17, 28	1, 2, 3, 4, 14, 15, 16, 17, 18, 19, 25, 26	13, 14, 15, 16, 17, 18, 21, 22, 23, 24	13, 14, 15	11, 12, 15, 16, 17, 18, 19, 20, 21, 30
шалкан	3, 13, 14, 15, 16, 17	2, 3, 14, 15, 16, 17	13, 17, 18	14, 15, 23	11, 12, 20, 21, 30
чөгендер	3, 13, 14, 15, 16, 17	2, 3, 14, 15, 16, 17	13, 17, 18, 24	14, 15, 23	11, 12, 20, 21, 30
помидор	3, 4, 7, 8, 16, 17	2, 3, 6, 7, 14, 15, 16, 17	2, 3, 4, 9, 13, 17, 18, 30	1, 9, 14, 15, 27, 28	5, 6, 7, 11, 12, 15, 16
кабак	3, 4, 5, 6, 7, 8, 16, 17	2, 3, 4, 5, 6, 7, 14, 15, 16, 17, 31	1, 2, 3, 4, 9, 13, 17, 18, 28, 29, 30	1, 9, 14, 15, 27, 28	5, 6, 7, 11
фасоль	3, 4, 5, 6, 16, 17	2, 3, 4, 5, 14, 15, 16, 17, 31	1, 2, 3, 4, 9, 13, 17, 18, 28, 29, 30	6, 7, 8, 9, 14, 15	3, 4, 5, 6, 7, 11, 12, 20, 21, 22, 30
сарымсак	3, 13, 14, 15, 16, 17, 18, 19, 20	2, 3, 14, 15, 16, 17, 18, 19, 25, 26	13, 14, 15, 16, 17, 18	13, 14, 15, 23	11, 12. 20, 21, 30

УҢЫШСЫЗ КӨННӘР

	10, 11, 12, 25, 26, 27	11, 12, 13, 27, 28, 29	10, 11, 12, 25, 26, 27	10, 11, 12, 24, 25, 26	8, 9, 10, 23, 24, 25

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА әзерләде.

Ун әдипкә – ун сорау: КАМИЛ КӘРИМОВ

1 ?

– Бүгенге әдәбият торышын ничек бәялисез? Кайберәүләр, укырлык әсәр юк бүген татар әдәбиятында, дип зарланырга ярата. Сезнеңчә ничек?

– «Кайберәүләр» дигән төшенчәгә алдан ук үземнең мөнәсәбәтемне белдерәм. Укырлык әсәр юк дип зарлана торган кеше ул – йә бүгенге көндә кулына яңа китап алып карамаган иске укучыдыр, йә чиле-пешле әсәрләре кире борылган уртакул язучы булыр.

Бүгенге иҗат дөньясында кытлык юк: элеккеге коммунист язучыларның төшенә дә кермәгән тарихи романнар хөррияте; сәяси интригаларга корылган повесть-хикәяләр; яңача әйләнеп кайткан детектив бәяннар; күренекле шәхесләрнең язмышын тасвирлаган биографик хроникалар; маҗаралы мәхәббәт кыйссалары; заманча юмор һәм сатирик сәхифәләр – җаның ни тели, ал да укы гына.

2 ?

– Заман белән бергә язучы да, аның җәмгыятьтә тоткан урыны да үзгәрә. Бүген язучы нинди булырга тиеш дип уйлыйсыз, аның миссиясе нәрсәдән тора?

– Без хәзер искиткеч каршылыклы чорда яшибез. Бик яшь шул әле безнең бүгенге җәмгыятебез. Ә яшьлек ул, үзегез беләсез, эзләнүләр чоры. Димәк, татар базар әдәбияты да эзләнүләр чорында. Социалистик реализм куенында буын ныгыткан күпчелек авторларыбыз базар телендә сөйләшә алырмы – анысы башка мәсьәлә. Әйе, шигъриятнең юлы – туры, сүзе коры, ул үзгәрешләрне бик тиз тотып алыр, кичәге кызыл төсләрне бүгенге яшел, күрән һәм ак төсләрне җиңел таркатыр. Чәчмә әсәрләр ашыкмас, прозабыз укып гыйбрәт алыр өчен генә түгел, сюжетлардагы язмыш белән яшәлгән очракта, үзеңне ни көткәнен юрау өчен дә кирәк.

3 ?

– «Язучы шулай булырга тиеш», «язучының бурычы шул» кебегрәк сүзләр еш яңгырый. Ә минә «язучының хәле ничек?» дигәне бик ишетелми. Язучы бүген нинди хәлдә?

– Татарстан язучылары арасында олигархлар юк. Шуңа күрә «хәл» дигәнебез – җан асрау бурычлары белән туган ил алдындагы бурычлар арасында. Пенсиягә чыкканнан соң да эш урынында ябышып тору рәхәт тормыштан түгел. «Хәлең ничек?» – дип сорасалар, «Аллага шөкер!» – дип җавап бирергә тырышабыз. Елмаймыйча гына. Елмайсаң, хәл сораучының ачуын китерүең бар. Хәзерге авторлар белән аңлашып эшләү өчен, редакциядә психиатр (психолог түгел) штаты булдырыр чак җитте.

4 ?

– Язучы хезмәтенә рәсми статус бирүгә ничек карыйсыз, аны нинди юллар белән җайга салып була?

– Язучылар оешмасында теркәлгән билетлы һәр язучы үзен профессионал дип исәпли ала, әгәр өйдә ятып кына җан асрый алса. Мин үзем 1983 елдан СССР язучысы, бу исемнең әле пенсиягә дә йогынтысы бар.

Иҗат итү хәзер байлыкка ымсынмаган фанатлар кулына калып бара. Рәсми рәвештә теркәлгән эшсезләр арасында хатын-кызлар күбрәк. Шуңа күрә әдәбиятка да хатын-кызлар төркем-төркем килә. Ә ир язучыларның күбесе йә шабашник, йә китабын сатучы вак сәүдәгәр. Төрләр һәм хәлле бизнесменнар турында китап язып шабаючә абзыйларыбыз да шактый.

5 ?

– «Хәзерге заман укучысы» дигәнрәк сүзне бик еш кулланалар. Бу төшенчәне сез ничек кузаллыйсыз? Кем ул бүгенге заман укучысы, нинди ул? Гомумән, укучылар да заманга карап үзгәрәме, аерыламы?

– Инде сер түгел, авторларның саны арткан саен, абунәчеләрнең һәм китап укучыларның саны кими бара. XX гасыр башында да нәкъ шундый күренеш булган. 1905 елгы революциядән соң яңа ачылган татар матбагаларының саны йөзгә җиткән, тиражлары гына 200-500 данәдән артмаган. Алтмыш-җитмеш ел үзгач кына матбугат үсеше үзенең иң югары ноктасына җиткән. (100 мең, 380 мең, хәтта миллионга җиткән данәле журналларыбыз бар иде.) Күп еллар үткәнне сабыр гына көтеп карыйк әле. Бүген без ерак тарихны сагынып, кичәгене сүгеп, бүгенгеләрне үсендереп иҗат итәбез. Талантлы язучыга талантлы укучылар кирәк. «Ширпотреб» әсәрләр белән артык мавыкмыйча, классика эталонын саклап иҗат итә алсак, матур әдәбият исән калыр.

6 ?

– Язучының иҗади үсешендә әдәби тәнкыйтьнең роле бар дип уйлыйсызмы? Әдәби тәнкыйть бүген нинди хәлдә һәм аның үсеше өчен нәрсәләр эшләргә мөмкин?

– Бүгенге авторларыбыз укымышлы һәм дә калын тиреле. Берәүнең дә әле мин уртакул язучы дигәнен ишеткәнем юк. Исемлектәге 300ләп язучының һәркайсы үзенчә даһи, теге яки бу кимчелекләрен танырлык итеп, теория кушканча язарга өйрәтәм димә… Ләкин әдәби әсәрләрен бәяләгәндә, бөтен язучылар да бертигез хокуклы була алмый. Талантны – графоманнан, уңышны – кимчелектән, оригинальны– компилятивтан, матур әдәбиятны суррогаттан аера белү өчен кирәк ул тәнкыйть. Тәнкыйть – язучы белән укучыны таныштыручы, тәнкыйть – реклама коралы.

7 ?

– Әсәрләрне тарату, китап сәүдәсе. Бу өлкәдә сез нәрсәләр үзгәрүен теләр идегез? Әллә ул шушы хәлендә дә бик уңышлы эшлиме?

– «Кулланучылар кәрҗине»нең бәясен чыгарганда, әдәбият тауары саналмый… әлегә. Инфляция, кризис, эшсезлек, мөлкәт тигезсезлеге һәм эш урынындагы җитәкчеләрнең авторитарлыгыннан йомылган халыкны китапханәләргә куып кертеп булмый. Репрессия чоры үтәр әле һәм тагын элеккечә китап сөючеләр җәмгыяте, матур әдәбиятны пропагандалау бүлекләре, гигант төзелешләрдәге әдәби постлар, чиратлары ташып чыккан китап кибетләре тагын әйләнеп кайтыр дип ышанам… Хөкүмәтнең бүгенге ярдәменә шөкрана кылып, сабыр гына иҗат итик.

8 ?

– «Язучы һәрвакыт укучылары белән аралашырга тиеш» дигән сүз бар. Сез моңа ничек карыйсыз? Укучыларыгыз белән аралашып торасызмы? Аның өчен нинди мөмкинлекләрне файдаланып була?

– Юлдан кайтып кергән юк. Редакциядә утырып кына тираж җыеп булмый. Мәктәпләрдә, китапханәләрдә, мәдәният йортларында әдәби кичәләр оештырып, яңа чыккан әсәрләр белән таныштырабыз, үзебезнең барлыкны исләренә төшереп торабыз. Әлеге чаралар редакциянең төп эшенә әйләнеп бара бугай…

9 ?

– Яхшырак язу өчен язучыга нинди шартлар тудырырга кирәк дип уйлыйсыз?

– Әби-бабайларыбыз, әтиәниләр һәм абый-апалар язмышын язып, укучыны куандырдык. Инде үзебезнең биографиябезне дә баетасы һәм дә иҗат географиябезне киңәйтәсе иде. Һәр язучының да еракка дәшә торган берәр хыялы була. Ах, иҗади командировкаларны күпләп оештырасы иде шул хыяллар ягына…

Уренгойдан ерак түгел генә бер бистәдә, Җир асты хәзиналәрен барлау әмере белән, татар егетләре бик тирән скважина бораулыйлар. 12 мең метрга (!) төшкәннәр ди инде. Ниләр генә юк ди анда! Күрәсе, өйрәнәсе, язасы иде шул язмышларны, шул ачышларны…

10 ?

– Соңгы вакытта нинди әсәр язасыз? Бу әсәр нәрсә хакында? Аны кайдан табып укырга мөмкин (булачак)?

– «Күләгәдә төлке бар» (ТКН-1990) дигән китабым чыккач, «Мәдәни җомга» газетасы аны үзенә рубрика итеп алды. «Ком сәгате» романымның исеме белән сөекле каналыбыз яңа телевизион сәхифә ачты. «Тургайлы болытлар» дигән роман-элегиямнең икенче китабын да төгәлләп укучыларыма җиткерә алсам, бәлки, тагын берәр матбагада яңа рубрика пәйда булыр иде…

Азат Абитов:

«Авылга кайтып китмәкче идем, Ваһапов фестивале алып калды»

Азат Абитов тамашачы күңелен «Үткән көннәрне сагынмыйм», «Җәйнең кичләре», «Сиңа тагын мин бер киләм әле» җырлары белән яулап алды. Яшь җырчы Чувашиянең Батыр районы Шыгырдан авылында туып-үскән. Хәзерге вакытта Азат беренче зур сынавы – Казан концертына әзерләнә. 28 февраль көнне – Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе концертлар залында имтихан тотачак.

Алисә САБИРОВА

– Азат, тиздән тамашачыларга тәүге концертыңны тәкъдим итәсең. Шундый зур вакыйга белән котлыйбыз сине! Әзерлек эшләре ничек бара?

– Әзерләнгәнгә күрәдер инде, борчылырга вакыт юк. Көне җиткәч, сизелә башлый инде ул. Концерт татар моңы, халык җырларының үзенчәлекләрен саклап эшләнелде. Көчле музыкантлар төркемен җыйдык. «Сиңа тагын мин бер киләм әле» җырын бөтенләй башка яңгыраште ишетәчәксез. Ул саксофон белән дуэтта башкарыла. Концертымда иҗатташ дусларым Гөлсирин Абдуллина, Рәнис Габбазов, Артур Шөгаепов катнашачак. Остазым Венера Ганиева белән дуэт башкарачакбыз. Гомумән, минем өчен дә, тамашачы өчен дә зур яңалыклардан торачак бу концерт. Әйтик, миңа җырлаган вакытта тик басып торасың, дип әйтәләр иде, менә хәзер биергә өйрәнәм. Җиңел түгел, ләкин тырышам.

– Туган авылың Шыгырданда да концертың була бит.

– Әйе, иң беренче концертым, Алла боерса, 22 февральдә – Шыгырданда. Рәхмәт якташларга, билетларны берничә көндә алып бетерделәр. 23 февраль өстәмә концерт куйдык, анысына да билет бетеп бара инде, диләр. Шатланам да, дулкынланам да.

– Безнең редакциядә узган бер түгәрәк өстәлдә «продюсерга әтиеңә ышанган кебек ышанырга кирәк» дигән идең. Рифат Фәттахов белән сез чыннан да әтиле-уллы кебекме? Аның нинди киңәшләрен истә тотасың?

– Контракт төзегән вакытта, ул миңа бер сүз әйтте: «Нинди генә уңышка ирешсәң дә, тукталырга ярамый. Һаман үсештә булырга, алга барырга, эшләргә дә эшләргә кирәк», – диде. Мин шул киңәшне гел истә тотам. Ул миңа чыннан да әти кебек. Концерт булмаганда, миңа әтием көн саен диярлек шалтыратып, хәлемне сораша. Ә иҗат эшләремдә һәрвакыт Рифат абый белән элемтәдә торабыз. Бик күп эшләремдә ул миңа ярдәмче, төп терәк, ә кайвакытта пыр туздырып сүгеп тә ата. Әтиләр кебек инде!

– Җыр-моңга сәләтле, зур сәхнә дип хыялланучы егет-кызлар Ваһапов фестиваленә ничек эләгә ала? Үз мисалыңда сөйләп китсәң иде.

– Бу фестиваль минем күптәнге хыялым, ләкин анда катнашу өчен гариза бирергә гел соңга кала идем. Бер елны шулай Венера апа Ганиева оештырган «Сандугач-Соловей» бәйгесендә катнашырга туры килде. Шунда беренче турны да үтә алмыйча, төшенкелеккә бирелеп кайтып киттем. Әти-әнигә рәхмәт, үземдә янәдән ышаныч табарга алар ярдәм итте. «Бу әле җиңелергә сәбәп түгел», – дип, әти көнтөн репетициягә ясатты. Тавышымны яздырып, Ваһапов фестиваленә җибәрдек. Минем бит әле ул вакытта музыкаль белемем дә юк иде, бәлки җиңәргә шул үзенчәлегем дә ярдәм иткәндер. Ә сәхнәгә омтылучы яшьләргә мин төрле конкурсларда үзләрен сынап карарга, чыныгырга, тәҗрибә тупларга киңәш итәм. Иң мөһиме – үзеңә ышанырга кирәк.

– Димәк, Ваһапов фестивале синең тормышыңда зур роль уйнады?

– Хәлиткеч, дип әйтсәң дә була. Уңышсызлыкларга очрагач, мин инде авылга кайтып китәргә җыенган идем. Ә менә Ваһапов фестивалендә зур уңышка ирешкәч, бигрәк тә Рифат абый хезмәттәшлек тәкъдим иткәч, үземдә ышаныч тойдым. Казанда мине Ваһапов фестивале алып калды.

– Синеңчә, бүгенге җыр сәнгатендә кем кемне тәрбияләргә тиеш: җырчы – тамашачынымы, әллә тамашачы – җырчынымы?

– Җырчы – тамашачыны. Рәшит Ваһапов та, халыкны җырчы үз артыннан алып барырга тиеш, дигән. Халык күп бит ул, фикерләр дә төрле. Үз кыйблаңа тугры булып калырга кирәк.

– Бүгенге көндә син бит Казан мәдәният институты студенты да әле.

– Әйе, профессиональ музыкаль белем алу – продюсерым Рифат Фәттаховның беренче шарты иде. Икенче югары белем булгач, Ваһапов фонды мине үзе түләп укыта. Профессор Венера Ганиева классында укыйм. Бу — бик зур бәхет тә, зур җаваплылык та. Венера Әхәтовна бик кайгыртучан һәм бик таләпчән кеше.

– Кем белән дуэт җырлар идең?

– Илсөя Бәдретдинова белән җырлыйсым килә. Безнең стильләр туры килә. Шәп дуэт чыгар иде. Мин инде аның тематикасын да уйлап куйдым. Ул авыр мәхәббәт турында булырга тиеш. Ирина Аллегрова белән Григорий Лепс җырлый бит әле, шуның кебегрәк.

– Кайвакыт миңа әрсезлек җитми дисең, мишәр егете әрсез була аламы инде?

– Үзем дә шаккатам (*көлә*). Гаиләдән, тәрбиядән дә киләдер. Дөрес, үземнекен бирми торган сыйфат бар миндә. Сәхнәдә дә, тормышта да әрсезлек кирәк. Тәҗрибә белән бу сыйфат та килер дип уйлыйм.

– Җырлаудан кала тагын нинди сәләткә ия булыр идең?

– Авыр сорау. Нәрсә телим икән мин?.. Бәлки, яхшы актер булыр идем. Соңгы арада бу бик кирәкле сыйфат.

– Гаиләң белән дә таныштырып кит әле.

– Әти район мәдәният йортында тавыш операторы булып эшли, баянда уйный. Әни мәктәптә музыка дәресе укыта, шулай ук музыка мәктәбендә баян дәресләре бирә, җырлый. Абыем да, сеңлем дә җыр-моңга гашыйк. Иң беренче булып, абый җырлый башлады, хәзер аның гаиләсе бар инде. Сеңлем фортепианода уйный. Мәктәптә эшләгәч, андагы концертларны оештыруны әни үз кулына ала. Мин дә кайтырга тырышам.

– Син бит әле футбол белән дә кызыксынасың. Уйнарга яратасыңмы, әллә караргамы?

– Биш елга якын футбол уйнамаган идем, хәзер кабат кайттым. Үзем дә уйныйм, приставкада да, телевизордан да күзәтеп барам. Фәнил һәм Илшат Вакказов, Газинур Фәйзуллин, Рамил Шәрәпов, Инсаф Бәдретдинов белән «Ак буре» спорт комплексында атнасына ике тапкыр җыелышабыз. Җәй көне «Хезмәт резервлары» стадионындагы мәйданны арендалыйбыз. Футбол уйнап ял итәм. Көнегүләрне зарыгып көтеп алам. Мәктәптә укыганда баскетбол, волейбол уйнадым, кыска дистанцияләргә чабарга яраттым. Менә әле чаңгыда йөрергә хыялланам. Мин яшәгән җирдә чаңгычылар күп, кызыктыралар.

– Күбрәк акыл белән уйлап эш итәсеңме, әллә инде йөрәк кушканчамы?

– Күбрәк акыл, салкын баш белән эшләргә тырышам. Дөрес, кайвакыт хисләр дә өстенлек итә.

– Синең йолдызнамәңне укыган идем. Кәҗәмөгезләр тыштан кырыс, җитди кеше булып күренәләр, ә эчтән йомшак, сизгер күңелле кешеләр дип язылган. Бу дөреслеккә туры киләме?

– Әйе, дөрес әйтәләр. Тыштан күрсәтмәсәм дә, күп әйберне йөрәгемә якын алам. Дулкынланган вакытта күземә яшь килә. Концертыма әнине чакырган идем. Хәзер әни сүз әйтсә, еламасам ярар иде, дип куркам. Егетләр кызларга караганда да күбрәк елыйлар.

– Ә тәнкыйтьне күтәрәсеңме?

– Игътибар итмәскә тырышам, ләкин әйткән сүзләр турында уйлыйм. Тәнкыйтьнең дә төрлесе була бит. Әлегә миңа карата тәнкыйть сүзләре күп яңгырый. Белем булмагач, кемдер, дөрес җырламыйсың, ди. Сәхнәдә үземне тотышымны да ошатмыйлар. Кайберләре, елмаймыйсың, селкенмисең, ди. Минем беркайчан да сәхнәгә, бу куплетны җырлаганда болай эшлим, бу мизгелдә болай эшлим, дип чыкканым юк. Күңелем ничек куша, сәхнәдә дә шундый мин.

– Җырчыларны, артистларны тамашачы әллә нинди бүләкләр белән шаккатыра, иң истә калган бүләк нинди иде?

– Иҗатымны күзәтеп баручы Әлфия апа Хәлиуллина миңа һәрвакыт «ВКонтакте»да матур шигъри сәламнәр яза. Туган көнемә рәсем ясап җибәргән иде. Бервакыт ул минем концертыма килгән. Башта танымадым үзен. Концертта беренче рәттә утыра иде. Шунда кулыма пакет сузды. Өйгә кайтып ачып карасам, анда зур итеп Азат Абитов дип үз куллары белән чигелгән сөлге тора. Ул бүләк миңа бик ошады. Әлфия апага аның өчен зур рәхмәт.

– Синең кебек егеттән мәхәббәт турында сорамасам, гөнаһ булыр. Очрашып йөргән кызыңның нинди ялгышын беркайчан да кичермәячәксең?

– Минем өчен иң зур авырлык – хыянәт. Аны берничек тә кичереп булмый. Ә башка нәрсәләр турында уртага салып сөйләшеп, аңлашып була. Намуслы, тугры кешеләрне яратам.

– Иң соңгы укыган китабың?

– Мин, гомумән, китап укырга яратам. Соңгы китабымны Мәскәүдәге гастрольләрдән алып кайттым. Кунакханәдә буккроссинг киштәсендә Валентин Сафоновның «Отряд особого назначения» дигән сугыш турындагы китабын ошатып укый башладым. Икенче көнне китәргә туры килде, ә китаптан өзелеп кенә булмый бит. Шунда администратордан сорап, үзем белән алырга булдым. Кечкенәдән Гарри Поттер өчен үлеп китәм, аның бөтен китапларын укып чыктым инде. Күптән түгел, яңа бүлеге чыгачак дип ишеттем, шуны укырга хыялланам. Күрше малай белән фантастика, комикслар укый идек. Минем күзаллау зур, рәхәт. Кемдер кино карап ял итә, ә мин – китап укып.

– Тормышыңда иң дулкынландырган мизгел?

– Ваһапов фестивалендә катнашу, Мәскәүдә Кремль залында чыгыш ясау. Булачак концертым да шундый вакыйга булыр дип ышанам.

– Башка җырчылардан аерылып тору өчен нинди булырга тырышасың?

– Үзем булып калырга тырышам. Башкалар белән үземне чагыштырганым юк.

Ташлагыз да рәхәт яшәгез

КАЙТАВАЗ

Марат Кәбировның «Төрмәдән качкан шикелле... яки 30 ел тартканнан соң тәмәке ташлау тәҗрибәсе»н («ШК», 26 гыйнвар) укыганда, аның һәр сүзенә 21 еллык тәмәкече стажым белән пичәт сугып бардым. Бу темага минем дә күптән язасым килә иде... Тик «тартуны ташлагач, кешенең организмы никотин таләп итеп бәргәләнә башлый» кебек җөмләләр белән кеше куркытуына гына шикаятем бар. Организмда никотин балансы өчен барган эчке көрәшне тәмәке ташлаган кеше хәтта сизми дә!

vk.com

Тәмәке ташлаудагы бәргәләнү-өзгәләнүләрнең төп сәбәбе – акылда, башта. Ташларга уйлап та, «никотин газабы»ннан курыккан кешеләргә гади генә сорауларга: «Ни өчен төнгә кергәндә тәмәкече калтыранып кесәсен капшый, тәмәкесез калса, әсирлеккә эләккәндәй тыпырчына, йоклап китә алмый, кибеткә чыгып йөгерә, ә тәмәке алып кайтып куюга, иртәнге 10га хәтле гырылдап йокыга тала – никотин газабы ярты сәгать саен «типкәләп» уятмый?» дигән сорауга җавап биреп карарга киңәш итәм.

Нәтиҗә: әгәр син никотин ачлыгын йоклаганда сизмисең икән, нинди «газап», нинди «бәргәләнү» булсын инде ул?! Димәк, ул «газап» сизелмәслек дәрәҗәдә кечкенә...

Киңәш: тартуны ташларга җыендыгыз икән, ниятегезнең катгый булуына инаныгыз. Юкса, ташлап-башлап, психологиягез өчен ул хәшәрәтнең никадәр «кадерле» булуы турында иллюзиягезне генә баетачаксыз.

Тәмәкегә киткән акча, сәламәтлек, нервы (кызык, әмма, үзе үк «тынычландыра» торган «нервы»ны тәмәке үзе үк какшаткан булуын, хәтта шуның белән генә «әсирлеккә» алуын аңлау минем өчен чып-чын ачыш булды!) турында фикер йөртә башласагыз, тагын да күбрәк тарта башлаячаксыз.Чөнки бу уйлар – стресс, ә тәмәкече өчен стресс ул нәрсә? Дөрес, тагын тәмәке! Күбрәк уйлаган саен, күбрәк тартасың...

Тәмәкене ташларга чынлап торып ниятләгәнсез икән – туктагыз! «Соңгысын гына тартыйм, гомерлеккә хушлашам бит...» ише көфер уйлар белән үзегезне юксыну газабына этәрмәгез. Туктагыз да тәмәкесез яшәүнең никадәр рәхәт булуын, моңа кадәр никадәр җүләр булуыгыз турында минут саен белеп, эчке тыныч рәхәтлек тоеп яши башлагыз.

Гаиләгез, туганнарыгыз, якыннарыгызның сезгә карап соклануыннан җаныгызга рәхәт алыгыз. Бүгеннән башлап, сезнең авыздан сасы тәмәке исе килмәячәк, тартып бүлмәгә кергәч, сезгә берьюлы 15 кеше борынын җыерып карамаячак. Җәмәгать урыннарында, кунакта, аштa, концертта... сез «Кайчан бетә инде бу?» соравы белән арлы-бирле бәргәләнмисез... Кызкасы, тәмәке тартмау – газап түгел, ә бәхет, абруй, сөенеч!

Үзем дә өч елдан артык буе шушы рәхәтлеккә күмелеп яшим.

Алмаз МИРГАЯЗОВ,
Казан.

Әти, син безгә кирәк

Һәркем өчен дә үз әтисе иң яхшысы, иң якыны, иң үрнәге, иң батырыдыр. Ә минем әтием бик тә гади кеше. Шушы дүрт хәрефле сүзгә бар да сыя: әтинең холкы, яшәү рәвеше, әйткән сүзе, эш-гамәле.

Әтием Хәмит Мөхәрәм улы Сәрвәров 1946 елның 1 гыйнварында Актаныш районының бик тә матур табигатьле Уразай авылында дөньяга килә. Әнисе – минем әбием Хидая өчен икенче бала ул. Абыйсы Фәнит белән әбиемә терәк, авыр вакытларында киңәшче булып үсәләр. Балачагын искә алганда, әтиебезнең күзләренә яшь килә. Әбием аларны бер ялгызы тәрбияли. «Өстебездәге киемебез сәләмә, ашарга ризыгыбыз каты-коты», – дип сөйли әтием кайвакыт, үткәненә кайтып.

Актаныштан бик тә еракта урнашкан Кама Тамагы районы Иске Казиле авылы кызы Хәтимәне үзенә тормыш иптәше итеп сайлый әтиебез. Без өч балага гомер бүләк итәләр. Әтиебез гомер буе «Таулар» колхозында (хәзер «Нур» хуҗалыгы) электромонтер булып эшләде. Әле дә исемдә, авылда көчле җил булса, ут сүнә иде. Әти, тәүлекнең кайсы вакыты булуына, һава торышы нинди булуына карамастан, чөйдә эленеп торган сумкасын иңенә асып чыгып китә иде, утны яндырмыйча кайтмый иде.

Әти белән әни бик тырышып, өч баласына югары белем бирделәр. Хәзерге көндә үз гаиләбезне корып, матур гына яшибез, эшлибез икән, без моның өчен әти-әниебезгә зур рәхмәтле. Мәктәптә дә яхшы билгеләргә укыдык. «Өчле» алып кайтсак, әтигә ничек күрсәтербез, дип уйлый идек. Юк, ул безгә сукмады, хәтта каты кычкырып та ачуланмады. Әкрен генә, әлеге билгене ни өчен алуыбызны сорар иде дә, «Икенче көнгә төзәтелсен», – дип әйтә иде.

Кызганыч, әниебезнең генә гомере озын булмады. 58 яшендә каты авырудан вафат булды. Әнинең хәле авыр чакта да, әти гел аның янында булды. Әни яраткан ризыкларны пешерде, урын-җирен дә чиста тотты. Әнинең вафатына быел – биш ел. Әти ялгызы гына, туган нигезебезнең җылысын саклап, авылда яши. «Шунысы яхшы, өч балам да якында – Актаныштa гына яши», – дип сөенә әти. Барыбыз да җыелып кайткач, өебез ямьләнә. Төрле яшьтәге җиде оныгына, балаларына, кияүләренә, киленнәренә карап, әтием: «Аллага шөкер, балаларым үз янымда», – дип сөенә. Әтигә быел 71 яшь тулды. Киләчәктә дә туып-үскән нигезебезнең нурын, җылысын саклап, безгә төп киңәшче, таяныч булып озак яшәсә иде. Әти, син безгә бик тә кирәк.

Әлфия ГАБДЕЛКӘБИРОВА,
Актаныш.

«Шәһри Казан» газетасы, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Ирек Салиховның «БлагоДарение» яшь буын һәм социаль инициативаларга теләктәшлек күрсәтү хәйрия фонды белән берлектә, «Әти хакы» дигән бәйге игълан итә.

Җәмгыятьтә Әти ролен күтәрүгә, үрнәк гаиләләрне барлауга юнәлтелгән бәйгедә теләге булган һәркем катнаша ала. Моның өчен Әтиләрне данлаган язмаларны «Шәһри Казан» редакциясенә юлларга кирәк. Шигырьләр кабул ителми. Җиңүчеләрне фонд вәкилләре һәм газета хезмәткәрләре кергән жюри билгели. Конкурста 3 номинациядә 3 җиңүче билгеләнә. Җиңүчеләр, әтиләре белән бергә, Казанга чакырыла. **БҮЛӘККӘ – ӨЧ ВЕЛОСИПЕД!**

Номинацияләр:

«ҮРНӘК ӘТИ» – *әтиләр турындагы иң яхшы язма*

«ОЛЫ ЙӨРӘКЛЕ ӘТИ» – *тәрбиягә алынган балаларны тәрбияләүче гаиләдәге әтиләр турында иң яхшы язма*

«БАТЫР ӘТИ» – *ялгыз гына бала үстерүче, үстергән әтиләр турында иң яхшы язма*

Язмалар **2016 елның 12 декабреннән 2017 елның 31 мартына** кадәр кабул ителә.

Тулырак мәгълүмат **shahrikazan.com** сайтында

12+

Телевизорда Хәмдүнә җитми

Җәй көне Проспект базарына яшелчә, җиләк-җимеш сатарга чыгам мин. Узган җәйдә шунда кызыклы гына вакыйга булды. Бер сатучы Хәмдүнә Тимергалиеваны танымады. Җиләк алырга теләгән Хәмдүнә: «Бушатмыйча, чиләге белән генә бирегез әле», – дигән сатучы кызга. Ә сатучы исә җырчыны 7-8 метр ераклыкта урнашкан кибеткә чиләк алырга җибәргән.

Ак эшләпәсен Алла Пугачеваныкына охшатып кигән мөлаем йөзле Хәмдүнә Тимергалиеваны танып, бөтен базар «ах» иткән иде ул чакта. Күпләр җиләкне чиләге белән бирергә дә әзер иде үзенә. Тик җырчы бары тик Балык Бистәсе районының Олы Солтан авылы болынында үскән җиләкне сайлады шул. «Мин үзем дә җиләк җыярга бик яратам, бу җәйдә вакытым гына булмады», – дигән иде җиләкле дә, чиләкле дә булган җырчы.

Хәмдүнә Тимергалиева моңлы тавышлы Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйроваларның дәвамчысы булды. Ни өчендер талантлы өлкән буын артисларыбызны, шул исәптән Хәмдүнәне дә экраннарда сирәк күрсәтәләр хәзер. Күбрәк заманча җырлар яңгырый. Габделфәт Сафинның «Уфалла арбасы» кебек халыкчан җырлары да сирәк ишетелә. Салих Сәйдәшевнең Таҗи Гыйззәт сүзләренә язылган «Җәй айлары» җырын Илһам Шакиров башкаруында тыңларга бик ярата идем. Кызганыч, ул җырны аннан башка җырлаучы да юк. Югыйсә, гомерлек җырлар бит.

Рәис ИДРИСОВ,
Казан.

livejournal.com

«Тыпыр-тыпыр китереп баса Мәхәббәт ноктасына»?!

«Болгар радиосы» кысаларында янәдән сәнгать советы эшли башлавы турында ишеткәнсездер, мөгаен. Һәрхәлдә, җыр сәнгатенә якын кешеләр хәбәрдар. Сәнгать советы дигән нәрсә радио-телевидение тирәсендә булырга тиеш – монысына шик юк. Ни өчен совет чорында язылган җырлар сыйфатлы һәм бүген дә заманча яңгырый? Чөнки ул җырлар бик җитди сәнгать советлары аша узганнар.

Илфак ШИҺАПОВ

«Болгар радиосы»ның сәнгать советы ул чорлардагы кебек зур түгел,әлбәттә. Шулай да аның составына җырга кагылышлы, җыр өлкәсендә ни дә булса эшләүчеләр: композиторлар, шагыйрьләр, аранжировка ясаучылар, продюсерлар һәм кайбер башка белгечләр кергән. Шул исәптән мин бахырыгыз да. Ике атнага бер, кайвакыт ешрак җыелабыз. Бер җыелганда, 30-40 җыр тыңлана. Җырчының исеменә, данына карау юк – сыйфат, радио форматына туры килү кирәк. Билгеле тавыш режиссёры, аранжировка остасы, чын мәгънәсендә белгеч Айрат Шәйхетдинов үзе радио студиясенә эшкә килгән чорда эшләгән сәнгать советы эшчәнлеген искә ала:

– Иң беренче чиратта җырның сүзләрен тикшерәләр иде, кәгазьдән укып. Сүзләрдә әз генә җитешсезлек булса, җыр үтми, студиядә радио өчен яздырылмый да. Башкаручы кем булуга карамастан.

Бүген дә шулайрак. «Болгар радиосы»нда яңгыратырга дип башкаручылар җибәргән җырларның сүзләренә, мәгънәсенә – иң зур игътибар. Шунсыз булмый да. Чөнки нәрсә генә ишетмисең яңа яздырылган җырларда. «Күктә ага яшел болытлар…» – бу әле, урыс әйтмешли, так себе – шагыйранә ялган итеп кабул итәрлек сүзләр генә.

Нәрсә генә җырламыйлар бит. Менә Илнур Мусин дигән бер егет җыр җибәргән. Сүзләре компьютерда вак шрифт белән җыелган… 3 (!) бит. Ниндидер җитди мәгънә булса да ярар иде – юк бит, бары сүзләр тупланмасы гына. Үтмәде җыр.

Альфред Якшимбетов көе, Тимур Чернов сүзләренә язылган бер моңсуырак җыр. Кабатлана торган сүзләре:

«Бер-беребезне
оныттык без,
Яшәү яме керде күңелга».

Монысы ничегрәк була икән? Димәк, бергә чакта яшәү яме булмаганмы? Соң, сөен инде алайса! Кеше күңеле кара урман – тик җыр үтәде.

Алсу Нәбиева дигән бер кыздан җыр:

«Сине күргәч, йөрәк
әллә нишли,
Урыныннан куба, саташа».

Ничектер хастаханәдәге кардиология бүлеге исе килеп торган бу җырга да яшел ут янмады.

Раяз Фасыйховтан берничә җыр. Берсе – ниндидер яһүд көенә, икесе – Раязга хас булмаганрак диско стилендә. Ни дисәң дә, тавыш, аранжировка шәп. Без өйрәнгән Раяз түгел, әлбәттә, әмма бик сыйфатлы эшләнгән. «Мәхәббәт ул диңгез түгел, мәхәббәт ул – океан» дигән сүзләргә дә бәйләнәсе килми. Океан сүзенең татарчасы юк чөнки.

Гадәттә, тәкъдим ителгән дүрт-биш җырның берсе генә беренче тапкырдан худсовет аша уза. Нигездә, сүзләр аксый. Аранжировка, яздыру сыйфаты буенча да сораулар күп туа. Башкару – гомумән, аерым мәсьәлә. Нишләтәсең, беркемне дә җырлаудан тыеп булмый, андый закон юк. Үзем дә шул өлкәдә эшләгәнгәме, миңа хәзер бөтен татар кинәт кенә җырлый башлаган кебек тоела.

Озак еллар татар эстрадасы белән шөгыльләнүче, бик күп җырлар авторы, автор-башкаручы, «Аксу» компаниясен нигезләүче Рөстәм Сәрвәров белән сөйләшеп торабыз. «Беләсеңме, татар эстрадасы дигәч, әллә нәрсә эшли башладым. Күңел кабул итми. Әллә арыткан инде, булмый татар эстрадасын тыңлап», – ди. Рөстәм дә шулай дигәч инде…

Җырлар тыңлавыбызны дәвам итәбез. «Болгар радиосы»ның баш мөхәррире Илфар Кәримовның йөзендә бер генә хисе дә чагылмаган кебек. Тик ул бик объектив. Чөнки нинди булса да ярамаслык җыр «иләк» аша үтсә, аңа җавап бирәсе. Әхлакый яктан да. 200дән артык җыр сүзләре авторы, «Шәһри Казан» газетасының баш мөхәррире Гөлнара Сабирова һәр яңа җырны ниндидер эчке бер куркыну белән каршылый дияр идем. Чөнки, әйткәнемчә, нинди генә сүзләр ишетмибез ул җырларда. Гөлнара бик таләпчән, сүз – аның өчен изге. Кем әйтмешли, форсаттан файдаланып, Айсылу Габдинова башкаруында үземнең бер җырны да советка тәкъдим иттем. Аранжировка, тавыш яздыру – Айратныкы. Берничә сүз аркасында, минем җыр да үтмәде. Монда блат дигән нәрсә юк…

Тагын бер яңа җыр яңгырый. Салават Шәехов көе, Ләйсән Сабитова сүзләре:

«Ерак юлга чыгу һәм
көчле ярату
Җаннарыма бирә зур
шатлык.
Үткәннәрне уйлап һәм
шигырьләр юллап
Утәр микән минем дә
картлык».

Янә бер шедевр:

«Балалар үстереп, сөеп
һәм сөелеп
Синең белән килә яшисе!
Гомер буе шулай
Сөю дулкынында
Килә бит ул минем
эшлисе».

Гомер буе сөю дулкынында ничек эшләп булганын аңламаганга, болары да үтмәде. Бу сүзләрдән радионың реклама бүлеге вәкиле Сөмбел Йосыпова да йөзен сытып куйды.

Нәфкать Нигъмәтуллин биш җыр алып килгән. Марат Кәбиров сүзләренә Ризван абый Хәкимов язган «Өзгәләнә җаным» җыры җыелышны бераз җанландырып җибәрде. Инде тынычланып беттек дигәндә, Марат Мөхәммәтшин дигән егетнең Зиннур Тимергалиев сүзләренә башкарылган җыры егып салды:

«Аккош кебек очып йөри
Мәйданның уртасында.
Тыпыр-тыпыр
китереп баса
Мәхәббәт ноктасына».

Беразга барыбыз да сүзсез калдык. Бар да мәхәббәт ноктасына ничек итеп «тыпыр-тыпыр» итеп китереп басып булганын күз алдына китерде бугай, булмә шаркылдап көлүдән ярыла язды. Әлбәттә, үтмәде җыру.

30лап шундый җыр тыңлагач (ә аларның бары дүртме, бишесенәме генә «ярый» дигән тамга сугылды, дистәләгәне кире эшләргә җибәрелде, ә калганнары бөтенләй чүплеккә китте), Илфар: «Бүгенгә җитәр, киләсе атнага тагын тыңларбыз», – дип туктатты. Көздән бирле сәнгать советында катнашып шуны аңладым: кирәк булган бу эш. Әллә нинди акчалар түләсәләр дә яңгырамаячак җырлар күп тәкъдим ителә. Әгәр дә сыйфатсыз җыр үза икән, бөтен Татарстан тыңлый торган «Болгар радиосы»ннан ул яңгыраса, башкалар да: «Болай да була икән», – дип эшли башлаячак (хәер, эшләүчеләре дә җитәрлек, дөрес). Ә бит «Болгар радиосы» өлгә буларак кабул ителә. Шуңа монда бары тик сыйфатлы җырлар гына яңгырарга тиеш.

Тагын бер нәрсә бар: сәнгать советы тәкъдим ителгән җырларны сүзсез генә кире бормый. Сүзләр сыйфатсызмы, көе килмиме, аранжировка начармы – башкаручыга кимчелекләр җиткерелә. Кайберәүләр әйтелгәннәргә игътибар итә, кимчелекләрне төзәтә, җыр кабат әйләнеп килә. Менә бу инде нәтиҗә. Шулай булырга тиеш тә.

Күпмедер дәрәҗәдә продюсер буларак, башкаручыларга газета аша берничә киңәш бирергә дә рөхсәт итегез.

Беренчедән, бездә йөзләрчә профессиональ шагыйрь бар, интернет аша да искиткеч талантлы иҗатчыларны табып була, җыр сүзләренә аерым игътибар бирегез, белгечләр белән киңәшләшегез. Талантлар, профессионаллар күп татарда!

Икенчедән, көй яздыруны да профессионалларга ышандырыгыз.

Өченчедән, аранжировка ясауга да, тавыш яздыруга да бик мөһим эш дип карагыз. Акчасын барыбер түлисез – эшләреннән сыйфат таләп итегез. Юкса кайбер җырларның яңгырашы трамвай микрофонына яздырган кебек.

«Буш» җыр эшләгәнче, вакытыгызны, акчагызны, көчегезне кызганыгыз. Эшләгез, тырышыгыз.

…Илфар Каримов шалтыратты. Бу атнада тагын җыелабыз икән. Әгәр дә берәрегез ике-өч сәгать җыр тыңлап утыру җиңел һәм рәхәт нәрсә дип уйласа, ул бик каты ялгыша. Монысын үз тәҗрибәмнән чыгып язам…

6 ФЕВРАЛЬ– ДҮШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Жырлыйк әле!» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Серафима прекрасная» . Телесериал (16+)
10:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
10:50 «Канун. Парламент Җәмгыять» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Криминальный роман». Телесериал (16+)
13:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
14:00 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Без тарихта эзлебез» (6+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:10 «Морские истории команды Кусто». Мультсериал (0+)
17:00 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
17:30 «Елмай!» (12+)
17:40 «Икенче туй». Телесериал (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Татарлар»(12+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Кичке аш» (6+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Әдәби хәзинә» (12+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
